Ленар Шәех

# Җылытасы килә дөньяны...

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ш11

**Шәех, Л.М.**

Җылытасы килә дөньяны!.. : шигырьләр, поэмалар / Ленар Шәех ; кереш сүз авт. Зөлфәт. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 255 б.
ISBN 978-5-298-01950-7

Ленар Шәехнең бу китабында лирик һәм юмористик-сатирик шигырьләре, поэмалары урын алды. Ул үзенең тирән фәлсәфи фикерләре белән укучыны сискәндерә, уйландыра, нечкә юморы белән елмаерга мәҗбүр итә, туйганчы көлдерә.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01950-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Шәех Л.М., 2011

Хөрмәтле укучым!

*Мин бу китабымның кульязмасын моннан дүрт ел элек әзерләп куйган идем. Шул ук вакытта олпат шагыйребез Зөлфәт абыйга укытып карарга уйладым. Тел төбемдә сүз башы яздыру иде. Зөлфәт абый бу теләгемне бик сөенеп кабул итте. - Кульязмам белән танышып, хатыны Фирая апа аша үзенең фикерләрен язып та җибәрде...*

*Дөрес, еллар дәвамында китапның төзелеше бераз үзгәрде. Кайбер шигырьләрем «Дүртенче кат... Бишенче кат...» (Татарстан китап нәшрияты, 2008) җыентыгына кереп китте, яңалары өстәлде... Ләкин Зөлфәт абыйның иҗатыма биргән бәясе калды...*

*Ленар Шәех*

Үз хисләрем шикелле

Яшерен-батырын түгел, болгавыр заманда яшәп ятмышыбыз. Артык нечкәрә, хисләнә торган еллар түгел югыйсә. Әмма ни хикмәттер, дөньялар болганса, күңел дигәнең сүзләрнең, уйларның яктысына, нәфисенә сусаучан була. Кара, шомлы сүзләрдән җан чиркана, ул моңсу җырлы көйләрне, шигырьләрне тансыклый. Батыр шигырьләр түгел, матур шигырьләр кирәк адәм баласына мондый чорда. Андый әсәрләр лирика дип атала. Төче сүзләр хакында түгел, җан җылыткыч ягымлы, сак, саф сүзләр хакында сүз бара.

Бу хакта уйлануым очраклы түгел. Мин өр-яңа шагыйрь Ленар Шәехнең шигырь китабы кулъязмасын укыйм. Китапның исеме үк минем уйларымны куәтли: «Җылытасы килә дөньяны!..»

Әйе, изге теләк бу, шагыйрь туганкай! Яшәгән дөньябыз җылытуга күрәләтә мохтаҗ... Язган шигырьләребез бөтен дөньяны ук бер селтәнүдә җылыта алмас, әлбәттә. Әмма ул күңелләрне җылытсын, ә күңеле җылы кешеләр дөньяны җылыта лабаса.

Ленар Шәех сүзләрне ягымлы, ипле, моңлы бер шигъри тәртипкә китерә белә. Бу – чын шагыйрьлек галәмәте. Укыйм, шигырьдән шигырьгә күчәм. Мине якты моң озата бара. Һәм шигырьләр сиздермәстән генә моң-сагышка әверелә. Миңа җиңел, хозур!..

Без шигырьгә, шагыйрь иҗатына сәер таләпләр куярга иялэшеп киттек. Янәсе, шигырь көрәшергә тиеш! Һаман: «Көрәшчеләр кирәк!» – дип кабатладык. Янәсе, шул була инде ул чын гражданлык хисе!

Әгәр син замандашларыңның (һич югы, бер замандашыңның!) җанын җылыта алгансың икән, бу гражданлык бурычыңны үтәү түгелмени? Синең шигырең белән җанын җылыткан кеше батырлыкка, егетлеккә сәләтлерәк булса, аны рифмалы тезмәләр белән батырлыкка чакыруның нигә кирәге бар? Кемгә тансык калай кыңгырау шалтыравы?

Әлбәттә, шагыйрьне борчулы, фаҗигале хәлләр дә, тарихның шомлы мәлләре дә тетрәндерә. Ләкин ул бу хакта язганда истерикага бирелми, сукранмый-сүгенми, теш шыгырдатмый. Шагыйрьнең кичерешләре ипле, алар, галибанә сүзләр булып, синең күңелеңә күчә. Һәм син шагыйрьнең тойгысын аңлавыңа куанасың.

Ленар Шәех затлы сөйләм серләрен белә. Көндәлек тормыш ыгы-зыгысыннан тинтерәгән күңелне затлы сөйләм сафландыра, терелтә. Чын шигырьнең бөек көче әнә шунда. Мин, нәтиҗәләремне раслар өчен, Ленарның шигырьләреннән мисаллар китереп тормыйм. Чөнки, күңелемә хуш килгән юлларны мисалга китерә башласам, бу китапны баштанаяк күчереп чыгарга туры килер иде.

Шагыйрь китапны шартлы рәвештә биш бүлеккә бүлгән. Әйе, шартлы рәвештә. Югыйсә тоташ моңлы сүз агышын, бүлекләргә бүлеп булыр идеме? Теләгәндә, бу китапны тоташы белән бер поэма дип атасаң да, әллә ни хилафлык булмас. Күңел бөтенлегеннән килә бу. Бик тә кирәк булып, китапны темалар ягыннан бүлекләргә аера башласаң, аптырап калыр идең. Тематик бүлеп булмый бит бу китапны! Монда тема юк! Дөресе, тема бар һәм ул бер генә – кеше күңеле...

Монда милләт язмышы да, гашыйкның сагыштан көрсенүе дә бер үк дәрәҗәдә мөһим.

Бу иҗатның тагын бер сыйфаты күңелемә хуш килә: Ленар шигырьләрен фәлән-фәлән яшьтәге кешеләр өчен дип аерып язмый. Миңа калса, бу шигырьләрдән һәркем үзенә кирәкле җан җылысын табачак. Укучының ничә яшьтә булуы, аның тормыш тәҗрибәсе мөһим түгел...

Бу уйлануларымны «Кереш сүз» дип тә әйтәсем килми минем. Асыл шигырьләр тупланмасына нигә кирәк ул кереш сүз? Кереш сүз капкасыннан башка гына уз өр-яңа шигъри дөньяга, сүзләр тылсымыннан хозурлан һәм кинән!

Мин укый бардым һәм шигырьләрнең берсен дә ятсынмадым. Шигырьләр дә мине ятсынмады шикелле... Күңелемә бик якын хисләр ләбаса болар! Мин бу шигырьләрне үз хисләремне кичергәндәй кичердем... Китапны әле генә кулына алган һәм укый башлаган һәркемгә дә шул кичерешләрне телим!

*Зөлфәт,* шагыйрь,
Татарстан Республикасының
Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты

# Кызыл алма

МИН ЯРАТАМ, СИН – ЯРАТ*

*(җыр)*

Кышның суык бер көнендә
Очраштык без, күрештек.
Иреннәрне җылытырлык
Кайнар итеп үбештек.

Кушымта:

Мин яратам,
син – ярат.
Алланган
синең яңак.
Йөзеңдә ай
аклыгы,
Күзеңдә кыш
сафлыгы.

Йөрәкләр дә бергә тибә,
Сулышлар кушылдылар.
Ә күңелләр бер-берсенә
Изге сукмак ердылар.

Кушымта.

Барлык карны эретерлек
Бездә сөю ялкыны.
Дөньяга яз китерербез
Суык кышлар аркылы.

Кушымта.

*2002*

## БӘХЕТ ШУШЫ ИКӘН…

Чабып кына килдең. Кочакладың.
Бигрәк җылы, иркәм, кочакларың.
Кайнардан да кайнар иреннәрең,
Сихерләдең мине, сихерләдең.

Ояласың үзең, кызарасың,
Гөнаһсыз һәм серле кыз баласың.
Калтырыйсың үзең, туңган кебек,
Ярамаган гамәл кылган кебек.

Күзләреңә карыйм кыяр-кыймас,
Яшькелт-зәңгәр күзләр – карап туймас.
Елмайдың да уйчан гына шулчак…
Җылы, рәхәт, иркәм, синең кочак.

Эреп кенә бетә күрмә инде,
Тулып пешкән син бер хөрмә инде…
Кулларыңны куйдың иңнәремә,
Мондый йомшак куллар синдә генә…

Күпме көткән Бәхет шушы икән,
Мин яратам сине, сөям, иркәм!..

*2003*

* * *

Син чиргә сабыштырасың,
Син терелтә аласың.
Син – Сөю фәрештәседер,
Син – Гүзәллек Алласы…

*2003*

* * *

Син – оҗмахның алмасы,
Син – йөрәгем ярасы...
Чакрымнарга сузылмасын
Ике йөрәк арасы.

*2003*

* * *

Йоклаганда, иреннәрем:
«А… А… А…» – дип кабатлый.
Исемеңне галәмдәге
Һәр ялгыз йолдыз ятлый.

*2003*

* * *

Диңгездә йолдыз бармы? –
Кемнәр төшеп караган?..
Мәхәббәт ачы балмы? –
Кемнәр эчеп караган?..

*2003*

СИН ИКӘН…

Әтиең дә, әниең дә
Зарыгып көткән.
Ябалак карга ияреп,
Төшкәнсең күктән.

Күзләреңнән әллә инде
Йолдызлар үпкән?..
Алсу битләреңә гүя
Ай нурын сөрткән.

Саф кыш ихлас күңеленә
Аклыгын түккән...
Хыял гөленә уралып
Йөрдең син күптән...

Ак карларны уйнатучы

Тормыш-җил икән.
Күңелгә кунды ак бәхет,
Ул бит син икән!..

*2003*

* * *

Чарасыз кырыкка ярылдым,
Мин хәзер бер түгел, мең кисәк.
Бәхетле сагышка тарыдым,
Сагышны бәхетле ул дисәк.

Як-якка чәчелдем, таралдым,
Уйларым сәйләндәй сибелде.
Кырыгым кырыкта яралды –
Сибүчем, җыючым син инде!

*2003*

* * *

*Кызларга*

Күктән төшкән йолдыз-җаннар,
Кемнең сөйгәннәре сез?
Беләм, беләм, егетләрнең
«Аh!.. Аh!..» дигәннәре сез.

Күзләрегез очкын чәчә,
Елмаюлар – ягымлы.
Ихлас, серле көлүегез
Күңелемә кагылды.

Әгәр карашымны алсам,
Тиз югалырсыз кебек.
Якын барып сүз башласам,
Сез оялырсыз кебек.
Тик читтән генә сокланам,
«Тфү-тфү-тфү!..» – күз тимәсен!
Язмыш сезнең тормышларны
Бәхет белән бизәсен!..

Күктән иңгән иң саф җаннар,
Шат күңелле инсаф җаннар,
Тормыш сөйгәннәре сез...
Беләм, беләм, кемнәрнеңдер
«Сөям!» дигәннәре сез.

*2004*

* * *

Йөрәгем түзалмый ут өрә,
Җавапсыз мәхәббәт үтерә…

*2004*

БӘХЕТ КАРЛАРЫ

*(җыр)*

Тын гына, талгын гына
Бәхет карлары ява.
Бәхет түшәлгән юлдан
Кыз белән егет бара.

Кушымта:

Ап-ак бәхет карлары
Тәүге сөйгән ярларны
Искә төшерә.
Булса булсын аз гына,
Бер йомарлам наз гына
Җитә кешегә.

Кар ява бөтерелеп,
Саф сөю тели кебек.
Язмыш буйлап атлыйлар
Кайгы белмәс кыз, егет.

Кушымта.

Эзне карлар каплады,
Ник аерылдык шулай?
Теге кыз белән егет
Элек без идек бугай.

Кушымта.

*2004*

СИНЕҢ ИСЕМ

*(җыр)*

«Авылда ярым бар», – дисең,
Әллә чын, әллә юри.
Синең исем, дога булып,
Күңел түремдә йөри.

Кушымта:

«Яратам» да димисең син,
«Яратмыйм» да димисең.
Утка керсәм, суга керсәм,
Күңелдә синең исем.

Уемнан һич китмисең син, –
Исмеңне җанга уям.
Кая барсам, кайда йөрсәм,
Синең жылыңны тоям.

Кушымта.

Мин бәхетле син булганга,

Миндә сөю – канат бар.
Үлгәндә дә, иреннәрем
Исемеңне кабатлар.

Кушымта:

«Яратам» да димисең син,
«Яратмыйм» да димисең.
Утка керсәм, суга керсәм,
Күңелдә синең исем,
Күңелдә серле исем.

*2004*

* * *

Еллар арты еллар алышыныр.
Кабат көзләр килер. Октябрь.
Без таптаган юллар һаман шул ук,
Тик йөздә сыр, чәчләр акта, бел.

Синең күзләр карап тора сыман
Төнге күкнең уйчан катыннан.
Ак тынлыкта киттең. Шул мизгелдән
Күпме бәхет, сагыш татылган.

Исеңдәме?.. Әллә оныттыңмы?.. –
Ак кар ява иде ул көнне.
Ак дөньяда икәү генә калдык,
Күңелемдә нидер селкенде.

Селкенде дә, шуннан туктамады,
Биеп торды күңел кыллары.
Бер мизгелгә якынаеп алды
Ике җанның язмыш юллары.

Нәкъ бер мизгел, шул ләззәтле очкын
Бер көй булып калды йөрәктә.
Сагышлы җан өчен юаныч ул,
Иң кадерле, якты бүләк тә.

Исеңдәме?.. Әллә оныттыңмы?.. –
Ак кар ява иде ул көнне.
Ак дөньяны икәүләшеп гиздек,
Күкрәгемдә нидер селкенде.

Селкенде дә, шуннан туктамады…
Сары көзләр. Кабат октябрь.
Төшләреңә керсәм, аптырама,
Без атлаган юлны тапта бер,
Мин көтәрмен карлы чатта, бел.

*2004*

* * *

Оялмадың, кызармадың,
Үбеп алдың битемнән, –
Гомеремдә иң зур бәхет
Миңа бүләк ителгән.

Аптырадым. Авыз ачык.
Күзләреңә карадым.
Күңелемне очындыра
Сиңа килгән һәр адым.

Үзең бер дә оялмадың,
Мине генә кызарттың.
Йөрәктә сызылып яткан
Яраларны кузгаттың.

*2004*

## АЙЛАР УЗДЫ…

*(цикл)*

1

Бер ай узды. Утыз көн
Өметем өзелгәнгә.
Юләр йөрәк каккалый,
Таң нуры сизелгәндә.

2

Ике ай. Уф. Алтмыш көн.
Кәефләр, хәлләр мөшкел.
Юк, бу мәгънәсез төштер,
Өнемдә кил дә янга,
Сөюең белән өшкер.

3

Өч ай үтте. Туксан көн
Кояшым сүрелгәнгә.
Күңелемә яшь тула,
Төн нурга күмелгәндә.

4

Дүрт ай. Нәрсә әйтергә
Хәлне җиңеләйтергә?..
Ни дияргә белмим дә,
Онытырга телим дә… –
Наз-карашың күз алдымда,
Гөл-исемең телемдә.

*2003 – 2004*

## ТАҢ КЫЗЫНА

*А-га*

Син еракта.
Тонык шәүләң генә
Күз алдымда бии ялгызы.
Бүген дә кич.
Кояш баеп бара.
Кайчан киләсең соң, Таң кызы?

Мин берүзем.
Сине уйлый-уйлый,
Фикерләрем, уем чуалган.
Татлы хыял
Кояш белән бергә
Ак офыкка китеп югалган.

Юк, кирәкми
Якты йолдыз, ае.
Юк, кирәкми төнге манзара.
Кичке салкын
Тәнне чымырдата.
Кайчан киләсең соң, җан ярам.

Керфек какмыйм.
Алсу таңны көтәм.
Вакыт ага. Күңел ялгызы…
Сине эзләп,
Ак офыкны күзләп,
Төнге юлга чыгам, Таң кызы…

*2004*

* * *

Уйларымны тараттың ла –
Ничек җыйыйм?
Сөюдән исергән башны
Кая куйыйм?..

Уйларымны чуалттың ла –
Ничек сүтим?
Йөрәгемне, әйдә, сиңа
Бүләк итим.

Уйларымны адаштырдың –
Каян табыйм?
Үземне үзем аңламыйм –
Кая чабыйм?..

…Айсыз төнне сискәндерде
Нур балкышы.
Уйларымны биләп алды
Сөю кошы.

*2004*

## СИН ГЕНӘ…

Син – өмет маягым,
Син генә,
Тылсымлы таягым –
Син генә.
Тормышым иртәсе –
Син генә,
Язгы җил иркәсе –
Син генә.
Ап-аяз күк йөзем –
Син генә,
Кояштай нур-күзем –
Син генә.
Чәчәгем, гөл генәм –
Син генә,
Язмышым, бер генәм –
Син генә.
Серле ай яктысы –
Син генә,
Ышаныч чаткысы –
Син генә.
Чәчәкләр хуш исе –
Син генә,
Гаҗәеп җәй киче –
Син генә…

Шулардан йокысын
Югалткан
Мәҗнүн җан миндер ул,
Мин генә…

*2004*

## СИНСЕЗ ЯШӘҮ*

*(җыр)*

Синсез яшәү бик тә авыр миңа,
Көнем моңсу, төнем караңгы.
Күңел яшем учка тамган чакта,
Кем дәвалар йөрәк ярамны?

Синсез яшәү бик тә авыр миңа,
Җанда сагыш-гамьнәр өеме.
Ак болытлар күмгән ак офыкта
Билгесезлек, томан төене.

Синсез яшәү бик тә авыр миңа,
Үзем генә беләм хәлемне.
Юлларыма килеп чыгарсыңмы,
Иңгә салып бәхет шәлеңне?..

*2004*

КЫЗЫЛ АЛМА*

*(җыр)*

Кызыл алма кулларыңда –
Кайнар кояш шикелле.
Шул алмаңны миңа суздың –
Йөрәк шашты, сикерде.

Битләрең дә алма кебек –
Тулып пешкән, кызарган.
Күңелеңә язлар килгән,
Бозлы кыллар кузгалган.

Елмаясың да көләсең,
Син язның үзе кебек.
Кызыл алмаң, серле алмаң
Күңелең күзе кебек.

Кулларыңда кызыл алма –
Ул синең ут-йөрәктер.
Тулы бәхет өчен минем
Йөрәк кенә кирәктер.

*2004*

* * *

Упкынга
ташланам –
Тик сине
ташламам.
Күктә ай
яндырам –
Тик сине
калдырмам.

Туңсам да,
мин китмәм –
Тик сине
өшетмәм.
Бүтәнне
ишетмәм,
Башканы
иш итмәм.

Авырлык-
лар килсен,
Мин какмам
тик берсен.
Түзәрмен,

чыдармын –
Гел сине
уйлармын.

Син көлсәң,
көләрмен.
Тик шуны
теләрмен:
(Бар уем
шул гына.)
Бәхетле
бул гына!

*2004*

## БӘХЕТЕМ ТУЛЫ ТҮГЕЛ

*(җыр)*

Әллә нәрсә булды безгә,
Ерагайды аралар.
Көннәр соры болытлардай
Әкрен агып баралар.

Кушымта:

Синсез барган,
Ялгыз ярган
Юлларым туры түгел.
Синнән башка
Дөньям башка –
Бәхетем тулы түгел.

Күңелемдә әрнеп тора
Сөю салган яралар.
Ялгышларны төзәтергә
Юк түгел бит чаралар.

Кушымта.
Әллә нәрсә булды безгә,
Ерагайды аралар.
Ә күңелләр әкрен генә
Бер-берсенә баралар.

Кушымта.

*2004*

## КӨТӘ-КӨТӘ...

Көтә-көтә көтек булдым,
Килмәвеңдер, мөгаен.
Уй һәм үзем тик утырам
Җирдә төн булган саен.

Уем гади уй түгел шул,
Анда син, тик син генә...
Көтә-көтә «үтүк» булдым,
Кил яныма, кил генә...

*2005*

## КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ АЛДАМЫЙЛАР...

Барысы да бетте, дисең,
Сүнеп бара сөю хисем,
Бәгырькәең янсын-көйсен,
Сине бүтән ярлар сөйсен...
Барысы да бетте, дисең.

Минем әйткән сүзләремә
Бераз колак салгалый бар.
Борыл, кара күзләремә –
Күз яшьләре алдамыйлар,
Күз яшьләре алдамыйлар.

Ачылган китап – йөрәгем,
Син – минем ныклы терәгем.
Минем бар тик бер теләгем –
Бергә булуны теләдем.
Ачылган китап – йөрәгем.

Гашыйк күңел буп-буш кала,
Син китсәң, аны туң ала.
Бер ярсый ул, бер тын ала –
Ничек синең җан туңала?..
Гашыйк күңел буп-буш кала.

Минем әйткән сүзләремә
Бераз колак салгалый бар.
Борыл, кара күзләремә –
Күз яшьләре алдамыйлар,
Күз яшьләре алдамыйлар...

*2004 – 2005*

## КАУРЫЙ СИБӘМ...

Йөрәгемне учлап кысам
Канат-кулыма.
Каурыемны сибеп үтәм
Киткән юлыма.

Каурыйларым – җаным минем,
Бәгырь үзәгем.
Син артымнан килсен өчен
Сыкрап өзәмен.

Шул юлымнан, бәлкем, мине
Эзләп табарсың.
Сөю тулы күзләремә
Сөеп карарсың...

Тик әлегә каурый сибәм
Киткән юлыма...
...Артка бактым –
            анда кемдер
Гамьдә коена.

*2005*

ЯКТЫ ТАВЫШ

Иртән тордым. Нидер җырлый кебек,
Нидер чыңлый кебек күңелемдә.
Моң-сагыштан мөлдерәмә күңел
Әзер тора ташып түгелергә.

Оча гына, шаша гына җаным...
Шул тавышка ятып эриме?..
Серле чыңнар-җырлар арасында
Бер күбәләк булып йөриме?..

Рәхәт шундый... Бәхет сөенече
Оялаган күңел эченә.
Моң-сихергә кереп барган саен,
Мин ышанам сөю көченә.

Якты тавыш, якын тавыш килә,
Таныш та ул тавыш, түгел дә... –
Күктән иңгән кояш тамчысыдай
Синең тавыш чыңлый күңелдә.

*2005*

ҖАНДА УЕЛ КЕБЕК...

Синсез үткән көнем бер ел кебек...
Шашып сагынудан тыел кебек...
Көзге яфрак булып коел кебек...
Тик хисләрем җанда уел кебек...

Тулып пештем кара муел* кебек...
Сөю үзе тоташ уен кебек...
Җылы кояш синең куен кебек...
Тик сөюем җанда уел кебек...

*2005*

* * *

Уйлама, уйнама, юрама...
Юраулар юш килә күрмәсен.

Батар да югалыр, туң алыр
Сөюнең Нух дигән көймәсен.

*2005*

## ЯРЫЙ, КӨТӘМ…

Төнлә йоклый алмый ятам,
Син дә йоклый алмыйсың…
Өзелеп сагынганымны
Тоясың күк, аңлыйсың…

Син дә мине сагынасың –
Бар җаным тоеп ята.
Күккә карап елмаясың –
Бар тәнем оеп ята…

Яныма киләсең кебек
Чәчләреңне таратып.
Авыз ачып карап торам,
Уем белән яратып…

Сагынудан күзләреңдә
Бәхет кояшы көлә.
Шулчак сине иркәлисе,
Сөеп-назлыйсы килә…

Төнлә йоклый алмый ятам,
Син дә йоклый алмыйсың.
Күзем ачсам, югаласың,
Нигә янда калмыйсың?..

…Уйларымда юртып йөри
Җаны йолдыз кашканың.
Ярый, көтәм ак хыялның
Ак тормышка ашканын.

*2005*

* * *

Сиңа
миңа караганда
Мең мәртәбә авырырак.
Синең өчен,
сөю өчен
Булыйм мәллә сабырырак?..

*2005*

## КИЛМӘ ИНДЕ…

Килмим, дисең, килмә, килмә,
Йомшак кулыңны бирмә.
Җылың көтеп моңсулансын,

Көзге яңгырга чылансын
Сиңа дип корган тирмә.

Килмим, дисең, килмә тагын,
Кисеп ат өмет ботагын…
Мең төргә керсен, кылансын,
Төнге суыкка чылансын
Сиңа дип корган табын.

…Киләм, дисең, килмә инде,
Тирмәне еллар җиңде…
Җылың көтеп моңсуланам,
Суык җилләргә сыланам… –
Күңелгә сагыш иңде.

*2005*

## УЛ ЯЗ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ГЕНӘ…

Кичералсаң, кичер, зинһар,
Үпкәләмә, сөйгәнем.
Мин сиңа бүләк итәрмен
Язның менә дигәнен.

Ул яз ямьле, озын булыр,
Гөлләр белән уралыр.
Икәү генә булган чакта,
Мәшәкатьләр югалыр.

Күктә генә очарбыз ла,
Тургай янәшәсендә.
Бәхет булып тирбәлербез
Ак хыял рәшәсендә.

Кулларыбыз кулда булыр,
Иңебез иңдә булыр.
Мәхәббәтнең иң зурысы
Синдә һәм миндә булыр.

Яшәрбез тоеп сөюнең
Наз-иркә көчен генә.
Ул яз безнең өчен генә,
Икебез өчен генә.

*2005*

## СӨЙГӘНЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

Бүгенге көн шундый якты,
Кояш иркә нурын сибә.
Рәхәт җылы арасында
Сөю тулы йөрәк тибә.

Җилләре дә бүтән бүген:
Язлы-назлы итеп исә.
Ак болытлар ничек түзсен

Зәңгәр күкне бизәмичә.

Сабыйларча көлү белән
Һәр мизгелне нурга бояш!.. –
Бик яшь чагың, көләч чагың,
Һәр елмаю – үзе кояш.

Кошлар булып очармын күк,
Бар хәятны кочармын күк...
Бәйрәм рухы били мине –
Сөйгәнемнең туган көне!..

*2005*

## АВГУСТНЫҢ СОҢГЫ КИЧЛӘРЕ…

Очрашу якынаямы,
Йөрәгем өтеп ала.
Һәрбер нурга чумган таңны
Зарыгып көтеп ала.

Синең йөрәгең дә сизә –
Күңелем тоеп тора.
Шарлавыктай вакыт көен
Көннәргә коеп тора.

Көннәр матурая бара,
Төннәр йокысыз үтә.
Акылымнан шашам бугай,
Очрашу көтә-көтә.

Кояш булып елмаясың,
Ай булып иркәлисең.
Иртәнге җил кебек җиләс,
Яз сыман иркә бит син.

Августның соңгы кичләре…
Җиргә яфрак коела.
Очрашу якынаямы –
Җанда җылы тоела.

*2005*

## ЛАЕШ?.. АКТАНЫШКАЧА!..

Актанышка кайтып барам
Чулманнан Лаеш аша.
Син якынрак булган саен,
Күңелем лаешлаша.

Юкса туры юлы да бар,
Никтер урыйсы килә.
«Нихәл?» – диеп, назлап-сөеп,

Синнән сорыйсы килә.

Әллә нишләттең дә куйдың,
Җаным гел сиңа тарта.
Лаеш шулпасы эчкәндә,
Гайрәт тә, көч тә арта.

Урыс капкасы янында
Мине көтәсең бугай.
Сириндәй зәңгәр офыкка
Карап үтәсең бугай.

Күзләреңдә тирән моң бар,
Чулманның серлелеге.
Күңелеңдә бу дөньяның
Мең дә бер төрлелеге...

Түзә алмыйм, томырылам
Чулманнан Лаеш аша.
Үзеңне дә алып китәм
Бүген Актанышкача!..

*2005*

СИНСЕЗ ТӨН

Сөю-назга әлсерәгән җаным
Сулып, кибеп, корып торган иде.
Ә өстемдә синең җылың калган,
Тәнең тәме калган юрган иде.

Синсез үткән айлы төннәр күпме,
Йомшак сагыз булып сузылган өн.
Ак каеннар шаярышып торган
Тәрәзәгә карап узылган көн.

Җитмәс иде бер кап кәгазь бите
Ничек сагынуымны җиткерергә.
Күз алдымда гына хыял чите –
Шәмем дә юк карап йөткерергә.

Йөткерергә, куып таратырга
Ак юл буйлап киткән вакыт җебен.
Тар тынлыкны бозып-бозып ала
Тар бүлмәдә кунаклаган чебен.

Түбәләрдән җәйге тамчы тама –
Агып беталмаган яңгырдан соң.
Моңсулыкка чумган синсезлекне
Бу төннәргә кемнәр чакырган соң?..

Төнне кисеп яңа кояш чыга,
Парлыларга гына ышык анда...
Ярый әле җылы юрганың бар
Ялгыз төннәремне ышыкларга.

*2005*

ПАР ЯФРАК

*(көзге җыр)*

Алмагачта ике яфрак
Яралды бергә.
Бар да шатлар. Рәхәт чаклар
Тик төшкә керә.

Кушымта:

Йөрәгемдә күптән калган
Төзәлмәс яра.
Бар үпкәләрне онытып,
Яратып кара.

Серләштеләр, сөйләштеләр
Җилләр эчендә.
Мәңгелекнең бер мизгеле –
Сөю өчен лә!..

Кушымта.

Яз буена, җәй буена
Үстеләр алар.
Шыбырдашып, сары көзгә
Күчтеләр алар.

Кушымта.

Гомерлеккә аерылмас
Төслеләр иде.
Икесе дә пар килгәннәр –
Көчлеләр иде.

Кушымта.
Җилләр килгәч кычкырдылар:
«Сөю – без инде!..»
Парлы яфрак, карлы яфрак
Төптән өзелде...

Кушымта.

Бирешмичә, килешмичә
Язмышлар белән,
Туң җиргә барып төштеләр
Сагышлар белән...

Кушымта.

Алмагачтагы пар яфрак
Таралды җилдә...
Кар эрегән
ике яфрак
Тиң сүнгән җирдә.

Кушымта:

Йөрәгемдә үткән алган

Төзәлмәс яра.
Бар үпкәләрне онытып,
Яратып кара.

*2005*

* * *

Дым астында басып торам –
Көзге яңгыр уртасында.
Соры-кара болытларны
Умырасы, ертасы ла...

Ташка бассаң, суы чыга,
Күпме була сибәләргә?
Көн-төн буе коя-коя,
Йөрәгемне телгәләргә?..

Соры көзнең күз яшьләре
Бетмәсә дә бетми икән.
Өянкенең ботаклары
Күшегүдән суга тигән...

Түбәләрдән тамган тамчы
Тып-тып килеп гомер саный.
Болай елак булмас иде
Ак биләүдә яткан сабый...

...Моң эчендә басып торам,
Җанда рәхәт, җанда җылы...
Саф мәхәббәт, сөю көче
Көзге яңгырлардан олы!..

*2005*

## ЯРАТАМ!..

Урамда ап-ак кар сибәли,
Әйләнәм ак карлар тирәли.
Очам мин, очам мин – тар-ра-там,
Яратам, яратам, яратам!..

Урамда энҗе кар сибәли,
Битемә ак карлар тигәли.
Әйләнәм, әйләнәм – тар-ра-там,
Яратам, яратам, яратам!..

Урамда ак бәхет сибәли,
Тирбәләм ак карлар тирәли.
Мин бүген бәхетле – тар-ра-там,
Яратам, яратам, яратам!..

*2005*

* * *

Ихлас яшьләр елтырыйлар
керфегеңдә,
Әрәм итмә, әрәм итмә
бөртеген дә.

Алда әле шатлыклары,
борчулары,
Тын кабарлык сулаулары,
тынчулары.

Янәшәдә күп көттергән
бәхете дә,
Шул бәхеткә сөенүдән
аһ итү дә...

...Саф елмаю кунып калган
керфегеңә –
Әверелгән якты бәхет
бөртегенә.

*2005*

* * *

Минем язмыш хата-ялгышлардан,
Сагышлардан гына үрелгән.
Янда көлгән якты кояш белән
Ул хаталар мең кат үбелгән.

Гомер сукмагыннан барган чакта
Мин үземне мең кат югалтам.
Алда әле, алда барысы да –
Күңелемне мең кат юатам.

Үз-үземне берәр табармынмы,
Уйлар чоңгылында авармынмы?..
Әллә инде салкын дөньясына
Кайнар ялкын булап кабармынмы?..

Телем-телем килгән йөрәк нишләр,
Кичererme мине, кичермәсме?..
Тып-тын һәм туң чынлык үрләреннән,
Бәхет түрләреннән төшермәсме?..

Минем язмыш хата-ялгышлардан,
Сагышлардан гына үрелгән.
Янда көлгән җылы кояшкаем,
Мин аларга бүтән үрелмәм!

*2006*

## КОҢГЫРТ КҮЗЛӘР...

Коңгырт күзләр... тирән уйчан күлнең
Беркем белмәс серен яшергән.
Сүзсез генә, күз карашы белән
Күп әйтелгән... күпме дәшелгән.

Эх, ул ымнар, эх, ул ишарәләр...
Күңелемә якын барсы да.
Мин аларны бик аз беләм, ахры... –
Ул карашлар моңлы, ярсу да...

Бер карасаң, шундый шаян алар,
Йолдызлармы анда биешә?..
Елмаюлар сине бизи генә,
Сөенүләр сиңа килешә...

Карашларың шундый моңсу кайчак...
Җиде биккә серләр ябылган.
И сөенәм гади сабый сыман –
Бер йозакка ачкыч табылган...

Күк йөзе бар синең күзләреңдә,
Уйчан күлнең тирән серләре.
Күзең яктысында
                    һаваларда
Аккош булып очып йөрмәле...

*2006*

## БӘХЕТЛЕ ЯТИМЛЕК

*(Сюлли-Прюдом мотивлары)*

Белсәң икән... күңелем ничек елый,
Мин берүзем утсыз яшим бит,
Юри генә яннан узып кит!..

Белсәң икән... җанны телеп ташлый
Офыклардан иңгән карашың,
Ник күзләрең тик бер карасын!..

Белсәң икән... җаннар күрешүе,
Үбешүе татлы өн бирә,
Ә күзләрең мине күрми дә...

Белсәң икән... кайнар учларыма
Йөрәгемне кыстым, нишләтим?..
Мин бәхетле, әмма мин ятим...

*2006*

## ШУҢАМЫ?..

Каеннарым шау яфракта,

Яфрак ярмый буламы?..
Мәхәббәте шундый көчле,
Шыбырдыйлар шуңамы?..

Миләүшәләр чәчәк аткан,
Чәчәк атмый буламы?..
Сөюдән шашкан гөлләргә
Күбәләкләр кунамы?..

Көйли-көйли яңгыр ява,
Ә яумыйча буламы?..
Ярсый-ярсый агып ята
Гөрләвекме, елгамы?..

Зәңгәр күктә кояш көлә,
Елмаймыйча буламы?..
Кояштай балкып киләсең,
Яратасың, шуңамы?..

*2006*

* * *

Үпкәләттем сине юкка,
Уйламый-нитми генә.
Күкне сарган кара болыт
Таралмый-китми генә.

Яңгыр ява шыбыр-шыбыр,
Әллә синме еладың?..
Күзләреңне мөлдерәтеп,
Сынадың да сынадың…

Әйтелгән сүз – аткан ук, ди,
Җаныңны кимергәндер.
Ай нуры сеңгән хыялны
Телгәндер, җимергәндер.

Үпкәләттем сине юкка,
Аңладым, соң аңладым.
Ник алдан ук иренеңә
Тамчы булып таммадым?..

Нигә күптән гөл булмадым
Син узган юл чатында?..
Менә хәзер кыл өстендә
Өмет кенә атына…

Өзелмәсә ярар иде…
Юк, беркайчан тынмамын.
Нигә синең баш очында
Кояш кына булмадым?..
Нигә назлы кулларыңа
Ак кар булып яумадым?..
Аңладым мин барысын да,

Соңлап кына аңладым.

Пар каплаган тәрәзәңне
Яңгыр булып ялмадым…
Ә болытлар арасында
Йөрәк тоя җан барын…

*2006*

* * *

Син мине ишетмисең,
Әллә соң иш итмисең?..
Иштем лә ишәк чумарын... –
Бергәләп ишикме соң?..

*2006*

* * *

*(Тулай торак бүлмәсендәге уйлану)*

Син киткәч күңелсезләнәм,
Син киткәч уйга чумам.
Гамь ташыган карашымны
Тагылар яңгыр юган.

*2006*

### МСЯ!..*

Сөюдән тилергән җаныма
Сөенеч, ак бәхет, моң сыя...
Кил әле, җимешем, яныма –
МСЯ!..

Чәчкәдәй өзелеп көткәнем,
Гөлләргә сабышкан җан тоя.
Бәгырем, сагынып беткәнем –
МСЯ!..

Елларны йомарлыйк учларга...
Хөр яшьлек юлларга наз коя...
Язларда, җәйләрдә, кышларда –
МСЯ!..

*2006*

### ЯРЫЙ ӘЛЕ СИН БАР...

Аккошның да пары бар,
Елганың да яры бар.
Җәйнең җылы яңгырлары,
Ә кышның ак кары бар.

Минем син бар,
Ярым – тиң бар.
Ярый әле
Син бар, син бар...

Кояшның нурлы ае бар,
Язның да ямьле мае бар.
Иренеңнең читләрендә
Бәхет кунган елмаю бар.

Кайгыларга баш имәскә,
Ак хыялга: «Хуш», – димәскә
Ярый әле син бар, җаным,
Син – барлыгым, алсу таңым.

*2006*

* * *

Җилкәй булып назлар идем
чәчләреңне.
Җил иркенә чәчәр идем
дәшмәвеңне.

Мин ышанам ул көннәрнең
килеренә –
Чыклар булып тамар идем
иренеңә.

Яңгыр булып юар идем
сагышыңны.
Минем күңел алышынды,
алышынды.

Юлларыңа гөлләр булып
түшәлермен.
Төнге күктән йолдыз алып
төшәлермен.

Мин барсына чыдармын да,
түзәрмен дә...
Өмет балкый, өмет яна
күзләремдә.

*2004 – 2006*

## СИҢА БАГЫШЛАНГАН ШИГЫРЬ

Һәр көн шигырь язар идем,
Сиңа гына багышлап...
Аңламыйсың: минем өчен
Син – мәңгелек табышмак.

Мәңгелек сер – карашларың,
Мәңгелек сер – уйларың.
Уйларымда тик син генә,
Сине уйлап туймадым.

Син дә мине уйлыйсыңмы,
Уйлап һич туймыйсыңмы?..
Шуңамы дәшмәвең белән
Җанымны кыйныйсыңмы?..

Мин гел шигырь белән уйлыйм,
Шигырь белән сөйләшәм.
Җырда, моңда янмас идем,
Әгәр сине сөймәсәм.

Күңелемне ачып кара,
Йөрәкне яр урталай –
Анда безнең икебезгә
Уртак кояш, уртак ай.

Бу шигырьне сиңа яздым,
Бары сиңа багышлап.
Син күктәге якты йолдыз
Кебек серле табышмак.

*2007*

* * *

Сине уйлыйм – син еракта,
Күңелемдә никтер моңсу.
Тар бүлмәмдә һава җитми,
Әллә нинди гамьле тынчу...

Тик суыткыч гөжләп тора,
«Мин бар ла, мин» дигән кебек.
Ак түшәмгә карап ятам,
Түшәме дә идән кебек...

Шыгырдавык сайгаклардан
Идәне дә түшәм кебек.
Гүя мин дә уйларымда
Синең янга күчәм кебек.

Уйлар, уйлар, чиксез уйлар...
Бер бүлмәмдә, бер еракта.
Алар шундый җитез була,
Син еракка киткән чакта.

Уйларымны бикли алмас
Җиде төндә җиде йозак.
Шуңамы син шундый якын,
Шуңамы син шундый ерак...

Түшәм-идән арасында,
Якын-ерак арасында
Исемеңне язып ятам

Төнге күкнең карасына,
Йөрәгемнең ярасына...
*2007*
* * *

Мин сине шунда ук сагынам,
Бер секунд, бер минут күрмәсәм.
Җаныма тынычлык табалмыйм,
Хәятны нурыңа төрмәсәң.

*2007*

* * *

Күңелгә яз кереп урнашты...
Әллә кайчан, туа-туганнан.
Елгыр еллар шаулап акса да,
Аерыла алмыйм мин аннан.

Күңелгә моң кереп урнашты
Җылы яңгыр битем юганнан.
Елдам вакыт җырлап барса да,
Аерыла алмыйм мин аннан.

Күңелгә чың кереп урнашты...
Зәңгәр кыңгыраулы урманнан.
Җитез гомер чыңлап чапса да,
Аерыла алмыйм мин аннан.

Күңелгә син кереп урнаштың –
Язны, моңны, чыңны бер иттең...
Аерыла алмыйм синнән мин –
Җаным белән сиңа беректем!..

*2007*

* * *

Бүләк итимме соң сиңа
Умырзаялар?
Кырыс язмыш кулларында
Кымырҗый алар.

Шаулап үсәләр иде бит
Салкынча җирдә.
Ходай аларга гомернең
Кыскасын биргән.

Сиңа телим мин гомернең
Озын-озынын.
Еллар аша барсын вакыт
Сузып-сузылып...

Мәңгелек умырзаялар
Үссен юлыңда.

Кояш нуры ялтырасын
Җылы кулыңда...

Сиңа диеп үстерәм мин
Умырзаялар.
Алар сиңа гына шулай
Шат елмаялар...

*2007*

ШАШКЫН ЙӨРӘК

Күкрәгемдә йөрәк
Мәхәббәттән шашкан.
Мин бит синең өчен
Күк капусын ачкан.

Мин бит синең өчен
Күктән йолдыз җыйган.
Якты йолдызларым
Күңелемә сыйган.

Мин бит синең өчен
Төнлә ай кабызган.
Айның бәгыреннән
Ап-ак нур тамызган.

Мин бит синең өчен
Әзер барсына да.
Шашкын йөрәккәем
Ничек ярсый әнә!..

*2007*

* * *

Мәхәббәттән качып булмый ла ул,
Мәхәббәткә булмый күз йомып.
Мин яратам икән – яратам мин! –
Моннан ары булмый сүз йолып.

Мәхәббәттә сүзләр артык алар,
Мәхәббәттә сүзләр кирәкми.
Нишләтергә ялкын чорнап алган,
Бәхет чолгап алган йөрәкне?..

Ярсу күңел өмет белән тулган,
Ташып тора утлы хис белән.
Мин яратам икән – яратам мин! –
Якты иртә, серле кич белән.

Сөям икән – сөям, бетте-китте! –
Йөрәгемдә ялкын шашына.
Мәхәббәтем белән чыгып басам

Тиле язмышымның каршына.

*2007*

* * *

Шомыртлар чәчәккә күмелгән,
Сириннәр күкләргә үрелгән...
Синме соң серле ай нурында
Җаныма моң булып түгелгән?..

*2007*

КҮЗЛӘРЕҢ...

Синең күзеңә карасам,
Бар дөньям онытыла.
Бу мизгелдә бөтен хәят
Бер мәлгә тынып тора.

Истән чыга бар мәшәкать,
Җанны биләгән сагыш.
Синең күзләр (минем өчен) –
Дөньяда иң зур табыш.

Синең күздә Чулман моңы –
Шаулары, дулкыннары.
Йөрәгеңне кыбырсыткан
Мәхәббәт ялкыннары.

Күзләреңә карыйм әле
Моңлы күзләрем белән.
Мин бит синең күзләреңнең
Яшерен телен беләм.

*2007*

* * *

Җәйге яңгыр яуганда да
Килә сине күрәсем.
Тамган һәр тамчы эчендә
Синең илаһи рәсем.

*2007*

ТУЙ КӨНЕНДӘ

Син минем бәхетем – мәңгелек,
Син ышан: сөюем мәңге нык.
Мин чабам яныңа... юк, очам –
Күзләрең бәхетле һәм уйчан.

Ыргылам һаваданмы? Судан?..
Бу җиргә син миңа дип туган.
Син мәңге минеке, минеке!
Без икәү күкнеке? Җирнеке?..

Барыбер анысы, бәхетем...

Мин сине сөюдән аһ иттем.
Мәхәббәт йөрәгем түрендә,
Син һәм мин ак бәхет үрендә.

Хыяллар сафтан саф, ак кына,
Елмаеп, шатланыр чак кына.
Сөенеч яшьләре күзеңдә,
Ак бәхет син бүген үзең дә!..

*2007*

* * *

Көн үтә, көн бара, көн чаба –
Вакытны тыярга чама юк.
Һәр мизгел, һәр минут, һәр сәгать
Мәхәббәт утында янаек.

Бер тамчы гомергә сыйсын ул
Бәхете, сөюе, шатлыгы.
Күңелгә керсен дә урнашсын
Дөньяның сафлыгы, аклыгы.

Кадерлем, матурым, җимешем,
Сөюне тыярга чама юк.
Кулларны кулларга куйыйк та,
Бәхетнең без үзен табаек!

*2007*

БЕЗНЕҢ ТУЙ КӨНЕ

Булдымы соң ул көн, булмадымы,
Күңелләрдә генә чыңладымы?..
Иртәләдеме ул, соңладымы,
Ә җаннарны татлы моң алдымы?..

Болыт булып агып китте димәм,
Аргамактай чабып китте димәм.
Барлык белән шушы көнгә иңәм –
Аңа бары бәхет кенә тигән.

Икәү атлыйк томан арасыннан,
Һәм күрсеннәр безне, карасыннар!..
Без икәү пар, мәңге түгел сыңар –
Алда язмыш йөз кат, мең кат сынар!..

Ә теге көн... бәхет, сөю тулы...
Минем кулда синең җылы кулың.
Эретерлек Төньяк полюс туңын
Куш йөрәктә типкән бер уч җылы.

*2007*

* * *

Минем йөрәк тип-тибә,
«Мин яратам!» дип тибә.
Көнең яңгырланмасын...
Бәхет тулы көннәреңне
Салкын яңгыр алмасын.

*2007*

МИН

Күктән чык булып төшкән болыт.

*2007*

СИН

Мәхәббәттән яралган чыклы умырзая.

*2007*

БЕЗ

Бер-берсенә уралып үскән ике үрмәгөл.

*2007*

* * *

Йөзең бүген балкып тора,
Чык суында юдыңмы?
Туй күлмәгең бик килешә,
Күлмәк белән тудыңмы?

Ак күлмәк – бәхет күлмәге,
Ул бит сафлыкның үзе.
Синдә әти-әниеңнең
Сөенеч тулы күзе.

Бүген кояш көлеп карый
Синең алсу битеңнән.
Йолдыз чаткылары балкый
Күзләреңнең читеннән.

Туй күлмәге – ап-ак күлмәк,
Берүк ул каралмасын!
Мәңгелеккә килсен берүк,
Бәхетең таралмасын!..

*2007*

* * *

Карыйм әле тын гына:
Күзләреңдә моң гына.
Ник болай моңланасың?

Күрдеңме моң анасын?..

Карыймын ялгыш кына:
Күзеңдә сагыш кына.
Нигә сагышланасың?..
Җаның сагыш алмасын!..

Карыйммы дәшеп кенә?..
Күзеңдә бәхет кенә.
Сөю сине үз иткән,
Күзләреңне дөньядагы
Иң бәхетле күз иткән!

*2008*

* * *

Ак бәхетләр яусын, яусын әле
Ап-ак карлар кебек.
Карлар гына безне никтер
Дөрес аңлар кебек.

Алар гына безне никтер
Үз итәрләр кебек.
Ә башкалар... алар
Сүз итәрләр кебек...

*2007 – 2008*

* * *

Синең күзеңә карасам,
Җанда өмет уяна.
Ә мин шуны күпме гомер
Белми йөрдем – дивана!

*2008*

* * *

Ләйсән яңгыр тамчылары
Тәрәзләрне үбәләрме?
Яңгыратып түбәләрне,
Яңгыр ява, яңгыр коя.
Җылы имән куышында
Без икебез корган оя...

*2008*

СИҢА

Күктә кояш көлә –
Сиңа бүләк итәм.
Ай да чыгып килә –
Сиңа бүләк, иркәм...

Йолдыз кабызам мин –

Алары да сиңа.
Күл буенда үскән
Таллары да сиңа.

Болын тулы чәчәк –
Кочаклап ал барын...
Сиңа бөтен дөнья,
Сиңа, сөйгән ярым!

*2008*

* * *

Сөйгәнем,
Яратам дигәнем!..
Күзеңнән үбәргә
Кыймадым, тимәдем...

Беренче
Айлы төн, серле төн.
Ай гына тынлыкта.
Ул тулган, бербөтен.

Йолдызлар
Җемелди. Күк якты.
Мәхәббәт үзе дә
Яп-якты нур чаклы.

Мәхәббәт
Үзе дә төн кебек...
Әкият тә кебек...
Барсы да чын кебек...

Сөйгәнем,
Язмышым дигәнем!..
Күзеңнән үбәргә
Кыймадым, тимәдем...

Оялдың,
Үзем дә кызардым...
Ул көннәр – үткәндә,
Мин инде кыз алдым.

Син минем
Янымда. Серле төн.
Ә безнең мәхәббәт
Ай кебек links бербөтен.

*2008*

* * *

Тышта яңгыр.
Янымда – син.

Төнне сүткән
Таңымда син.

Сине сөяр
Чагымда – син.
Син, син, син, син,
Тагын да син.

Тышта яңгыр.
Янымда – син.
Күптән инде
Җанымда син.

*2008*

* * *

Җаныңда күпме борчу бар,
Башыңда уйлар гына.
Үзем дә килеп сыенам
Борчу һәм уйларыңа.

Борчуларыңны таратыйм,
Кире кайтмаслык итеп.
Боек сагышлар эчендә
Мәңге батмаслык итеп.
Уйларыңа сөю кушыйм –
Бәхеттән торсын алар.
Ә уйларың мәхәббәттән
Ничекләр куаналар!

Үзең дә бит елмаясың,
Ихластан сөенәсең.
Белеп тордым ла мин синең
Күңелең сөенәсен!

...Җаныңны сөенечкә сал,
Мин генә булыйм уең.
Ни булса да, сөйгән ярым,
Минем куенга сыен.

*2009*

* * *

Дөньяның чынбарлыгыннан
Сине урлыйсым килә,
Кочак-кочак шигырьләргә
Сине урыйсым килә,
Синңа, миңа – икебезгә –
Бәхет юрыйсым килә...

*2009*

* * *

Мин, сиңа карасам,
Күземне алалмыйм.
Мин сиңа беркайчан
Карамый калалмыйм.

Йөзеңнең балкышы,
Күзеңнең нурлары...
Син барда языла
Битемнең сырлары.

Син янда булганда,
Күңелем яктыра.
Офыктан бәхетле
Киләчәк чакыра.

Эчкерсез иттереп
Иренең елмая...
Мәхәббәт артамы
Олгая-олгая?..

Сиңа бер карасам,
Карашым боралмыйм.
Мин сиңа беркайчан
Карамый торалмыйм.

*2010*

* * *

«Бер шигырь дә язмыйсың» дип
Үпкәлисеңме инде?
Күңелемнең кылларына
Чирткәлисеңме инде?..

Күзләрең дә мөлдерәмә,
Күзләреңдә гел сагыш.
Әйтәсеңме: «Хисләреңнең
Якасына син ябыш?..»

Хисләрне якалап булмый,
Иярләп тә булмастыр.
Алар җанны яктыртучы,
Мөгаен, бер кояштыр.

Хисләр, мөгаен, яңгырдыр,
Дулап исүче җилдер.
Мәхәббәттән генә алар
Киләләр җилбер-җилбер.

Яратудан гына алар
Чик-чаманы югалта.
Син янымда, шуңа минем

Хисләрем һаман арта.

Ташу булып көтә алар
Үз вакыты җиткәнен.
Ә мин хисләремә куйдым
Мәхәббәтнең җилкәнен.

*2007 – 2010*

# ХАЛӘТ

ИЛ ГИЗҮЧЕНЕҢ ТӨНГЕ ҖЫРЫ

*(Гете буенча)*

Тау өсләре йоклый сыман
Төнге караңгылыкта;
Үзәннәр дә күмелгәннәр
Тылсымлы бер тынлыкка.

Агачларның очларында
Сизелми җил сулышы;
Кошлар да тынып калганнар –
Ерак кояш чыгышы.

Юлда да тузан күренми,
Селкенми һичбер яфрак.
Чак кына көт, озакламый
Ял алырсың син азрак.

*2001*

ҖӘЙ ҮТЕП БАРА СЫМАН...

Кояш та иренеп карый
Болытлар арасыннан.
Ак толыпларга ияреп,
Җәй үтеп бара сыман.

Каен сары яфракларын
Бирә җилләр иркенә.
Җәйге көннәр, җәйге көннәр
Яфрак булып җилпенә.

Каз-үрдәк тә, моңаешып,
Канатын кага сыман.
Җәйнең күз яшьләре булып,
Күктән моң ага сыман.

Адашып китәрсең кебек
Төннәрнең карасыннан.
Төнге суыкка ияреп,
Җәй үтеп бара сыман.

*2003*

* * *

Күңелгә керә дә урнаша
Бер тамчы, бер бөртек гадилек.
Күңелем түрендә җырлаша
Тырышлык, дөреслек һәм ирек.

Чаларган өметне яңарта,
Гөлләргә күмелә җир өсте.
Гөнаһлы җанымны тазарта
Ирек һәм тырышлык, дөреслек.

Ялганны богаулый, фаш итә,
Җанымда мизгелгә тынычлык.
Күңелем аларны баш итә –
Дөреслек, ирек һәм тырышлык.

*2004*

* * *

Дөньяның сынауларыннан
Мин чиргә сабышмадым.
Маңгайга сыр булып ятты
Борчулар-сагышларым.

Сыналдым, тик сынатмадым,
Ак булды ниятләрем.
Чәчемә чал булып кунды
Кайгылар-хәсрәтләрем.

Күңелемне саклап калдым,
Мин аны ят кылмадым.
Күңелгә моң булып ятты
Бәхетләр-шатлыкларым.

*2004*

* * *

*(Фольклор экспедициясендә)*

Барысы да иртә таңнан шәһәрне карарга чыгып китте, мин генә, авырып, бүлмәмдә калдым...

Шабыр тиргә батып уйлап ятам:
Кайда ялгыш, кайда минем хатам?
Әстерханга килеп авыр, имеш, –
Ялгыз калулары авыр... имеш.

Тышта эссе, көне шундый ямьле,
Ә мин саклыйм черкиле бүлмәне.
Ак түшәмдә уйный кояш нуры,
Ә күңелдә – өметләрнең зуры.

Әни юк шул монда дәваларга...
Очам әле, очам һаваларга!.. –
Уйнак уйлар кайтса туган якка,
Басармын күк тиз-тиз мин аякка.

*2004*

* * *

Ава-түнә еллар аккан чакта,
Көтәм сине карлы-бозлы чатта.
Ни хәлең бар синең, Шигърият?
Үз артыңнан мине дә иярт!

Күңелләргә туң моң кунган чакта,
Сине көтәм хыял дигән катта.
Уйларым ак минем, ак ният,
Мин сынатмам сине, Шигърият!

Яз-наз илен эзләп тапкан чакта,
Туган якка казлар кайткан чакта,
Шатлыгымны бүләм, Шигърият.
Син бәхетле, беләм, Шигърият!..

Моңсу көзгә кереп барган чакта,
Йөрәгемне сагыш ярган чакта…
Мин һаман да сабый, ак ният,
Юат мине, юат, Шигърият!..

*2004*

НИЧЕК КЕНӘ ЯШӘП КАЛЫРГА?

*(Тукайны уйлап...)*

Кар өстендә ялгыз басып торам.
Ачучы юк миңа ишекне.
Ачынулы йөрәк авазымны,
Әрнүемне беркем ишетми.

Нигә ябык мин керәсе ишек? –
Җаным тулы сөю, ялкын бит...
Суланган кар аягымны кисә,
Кертегезче, бигрәк салкын бит!..
Дер-дер килә, калтырана тәнем,
Ни тере мин хәзер, ни үле.
Күзләремдә кайнар яшь дәрьясы,
Аяк асты – салкын боз күле.

Кар суыгы җан үзәгем буйлап
Йөрәгемә таба шуыша.
Үзәгемне өткән салкын белән
Күңелдәге ялкын сугыша.

Ачыгызчы!.. Зинһар... ачыгыз, дим!.. –
Җаным тулы сөю, ялкын бит!

Аяк бозга шакыраеп катты.
Тешем кысам: бигрәк салкын бит!..

Чуен тотка кадакланган ишек
Куркыныч та, үзе авыр да.
Котып кебек суык дөньясында
Ничек кенә яшәп калырга?..

*2005*

СИН ТАШЛАМА БЕЗНЕ...

*(Илдар Юзеевны юксынып...)*

Син ташлама безне, Илдар абый,
Ерак-еракларга китсәң дә...
Син кайтмассың инде арабызга,
Күпме генә өзелеп көтсәң дә...

Ак кар яуган олы юлга чыктың,
Фатихаңны безгә калдырып...
Зәңгәр моңың йөри йөрәкләрдә,
Җанны үтә сызып, яндырып...

Кыр үрдәге күптән кайтып җитте,
Кара каен хәзер ак кына...
Китабыңны ачып, шигырь укыйм,
Елый-елый укыйм, сак кына...

Шагыйрьләргә елау килешә ул,
Гомереңнән сагыш сүтсәң дә...
Син ташлама безне, Илдар абый,
Ерак-еракларга китсәң дә...

*2005*

* * *

– Нигә кәефең юк?
– Кояшка биреп җибәрдем.
– Ник?..
– Иртәгә кире әйләнеп кайтсын дип.

*2005*

* * *

Бозлар булып, карлар булып эри күңел,
Тамчы тама йөрәгемнең тибешедәй.
Кояш көлә зәңгәр дулкын уртасында
Бу дөньяның татлы, асыл җимешедәй.

Ничә айны кышлаган җан хискә чумган,
Гөрләвекләр салкынлыктан, туңнан калган,
Йөгерешә, берсен-берсе этә-төртә,

Төрле яктан – әллә арттан, әллә алдан.

Умырзая шытар тиздән, карны ярып,
Утка чумган йөрәгемнең көлешедәй.
Моң тарала, тын тарала һаваларга
Ярсу, дәртле гөл-җанымның өлешедәй.

*2006*

* * *

Көйләр көйләп көй әле бер,
Җырлар җырлап ян әле!..
Сулык-сулык йөрәккәем
Болай да бит яралы...

Шигырь сөйләп ачындыр бер,
Атылсын моң күңелдән.
Ул күңелләрнең түренә
Шанлы тарих күмелгән.

Әйдә көйлә, әйдә җырла,
Шаулы тормыш тынмасын.
Еллар үтсен, гомер барсын,
Ярты юлда сынмасын!..

Шигырь сөйлә, әйдә көйлә,
Теләсәң биеп җибәр...
Җанны төргән моң эчендә
Хәсрәтләр корыр, кибәр...

*2006*

ҖЫЛЫТАСЫ КИЛӘ ДӨНЬЯНЫ!..

*(триптих)*

1

Җәйгә кердек, ә мин туңып йөрим,
Табалмыйча җылы җаныма.
Бер кояшка сузам кулларымны,
Бер үреләм шырпы кабына.

Шундый салкын. Никтер аңлый алмыйм:
Җәйдә кышмы, кышта җәй мәллә?..
Суытамы әллә сөю юклык,
Ялгыш адым, гөнаһ гамәлләр?..

Бу дөньяга җылы эзләп килдем,
Бир син, җиһан, җылың, жәлләмә!
Болай да бит салкын.
                        Ялкын юктан
Гаҗизләнгән башым әйләнә.

2

Ут төртимме, әллә дөрләтимме,
Эсселәсен хәят, тирләсен.
Мин үзем дә җылы бирә алам,
Бирми икән дөнья, бирмәсен!

Мин үзем дә сөю бирә алам,
Күпме кирәк, мәгез, алыгыз!
Кесәгезгә акча итеп түгел,
Җанга ялкын итеп салыгыз!..
Мин үзем дә җылы бирә алам,
Тилмермәсен кеше, көтмәсен.
Яфрак хәтле гомер җылы эзләп,
Ялкын эзләп кенә үтмәсен!..

3

Яфрак кадәр гомер
                    җилгә очмас,
Мин ымсынам җәйнең таңына.
Җаным җылы, йөрәк кайнар әле,
Кояш ятмый шырпы кабында.

Яфрак кадәр гомер
                    җиргә төшмәс,
Күккә төшәр, бәлкем, кем белә…
Җылы бирәм сезгә, бер уч җылы,
Күпләр көтә, күпләр тилмерә…

Яфрак кадәр гомер
                    юкка чыкмас…
Мин ышанам…
                Тоям мин аны…
Бүтән мәңге суынмаслык итеп
Җылытасы килә дөньяны!..

*2006*

ИСТӘЛЕК

Хәятка яз инде, җан инде,
Мин һаман кышларда, кышларда.
Бер тамчы, бер бөртек кар алдым
Кышлардан агарган учларга.

Җылы җил сәламен җибәрә
Юлларда арыган кошларга.
Каралып карарлык каралык
Кояштай балкыган тышларда.

Ярсулык... Кар суык... Туң бәрә...
Кар суы тамчылый учлардан.
Язларны сеңдергән җанымда

Гөл калды – истәлек кышлардан.

*2006*

ПОСТМОДЕРН

Күңел поэзия эзли
Таш диварлар арасыннан.
Асфальтланган юллар буйлап
Шигырь чабып бара сыман.

Күңел җилли... Илһам эзли
Рельслар тимереннән.
Трамвайдан шигырь көтеп,
Меңенче кат тилмерелгән.

Күңел – яңгыр... Ул гамь эзли
Йортның калай түбәсеннән,
Асты өскә китерелгән
Бөек ханнар төрбәсеннән.

Күңел – ак кар... Ул моң эзли
Ипподромнан, стадионнан...
Шигырь түгел, дөнья чаба,
Мәшәкатьләр бара аннан.

Күңел поэзия эзли
Ярылган таш арасыннан.
«Ташгырь» төяп, «тимгырь» килә –
Илһамланмый карасыннар!

*2006*

* * *

Акыл сатмыйм бу дөньяга
туганнарга.
Акча белән бергә
юкка чыга
туганнар да...

Әйе, шундый якын булып
тоелганнар,
Үз булып, якты булып
җан-бәгырьгә
уелганнар

Гүя төтен, эндәшмиләр...
Телефон да
Чылтырамый.
Ишек каксаң,
җавап килми анда...

Тынлык кына...
Үз-үзеңне ялгыз итеп

Тоясың да ояласың... –
алар өчен –
җаның китек...

Бер кан ага, бер җан ага
димәссең дә.
Таш тынлыкка кагылырга
куркырсың да,
тимәссең дә...

Алар яши, син яшисең –
шул ук яшәү.
Өшетсә дә газиз күңелеңне
салкын дәшмәү.
Мин алар кебек түгел дип
юанасың,
Утырасың, уйланасың, гүя
су анасы...

*2006*

* * *

Мәхәббәтне таптым дисең,
Ул югала.
Мәхәббәтне тоттым дисең,
Ул ычкына.
Төнне ярып, ялгызлыктан
Кем кычкыра?..

Мәхәббәтне эзлим дисең,
Ә ул кача.
Син чабасың, ул йөгерә
Еллар аша.
Күңел көтә, күңел тула,
Күңел таша...

Кемдер эзли мәхәббәтен
Гомер буе...
Күзең төшер ярсу җанга,
Хисле җанга...
Мәхәббәтең ерак түгел,
Синең янда...

*2006*

ДӘҮ ӘНИЕМНЕ УЙЛАП...

*(цикл)*

* * *

Йомгагың тәгәри-тәгәри,
Сүтелә-сүтелә барды да...
Шул калын, шул ап-ак йомгактан
Бер чемтем нечкә җеп калды да...

Һәм вакыт беразга туктады,
Әйтерсең яшәеш йоклады.
Һавада эленгән ап-ак кар...
Тәрәздән ургылган ап-ак пар...

Җып-җылы ак болыт шикелле...
Тик бар да ишелде, ишелде...
Вакыт та йөгерде киредән,
Кышы да тилергән, тилергән.

Сүтелде, югалды ак йомгак...
Нигә соң нәкъ бүген дөнья ак?..
Кары да сибелде как җиргә,
Пары да таралды шом-җилдә...

Буранлый-буранлый, көн сүнде,
Ак карны җебетеп, яшь сеңде.
Урамдагы сукмак – ак йомгак...
Төн иңә, күгенә ак чорнап...

*2006*

* * *

Дәү әнисез калу авыр, беләм,
Нишләтәсең – тормыш кануны...
Бер дә ышанасы килми, әмма
Дөнья таләп итә тануны...

Барам, барам...
Ә син, күңелкәем,
Тик бер мәлгә әйләнеп кара... –
Еллар ага...
Газиз әнием дә
Дәү әнигә әйләнеп бара...

*2006*

* * *

Бүлмәң бигрәк бушаган,
Мәгарәгә охшаган,
Кайчак кысыла тыным...
Тик калган йөрәк җылың.

*2006*

* * *

Кемдер җитми җанга,
Кемдер җитми сыман.
Бәхет мизгелләрен
Нидер чикли сыман...

Кемдер җитми җанга...
Чыгып чабам төнгә.
Барып ышыкланыйм,
Елышыйм соң кемгә?..

Кемдер җитми җанга...
Йөрим юләр кебек.
Гүя үткән өчен
Кемдер түләр кебек...

Кемдер җитми җанга...
Хатирәләр генә,
Бүгенгене каплап,
Уй тавына менә...

Кемдер җитми җанга...
Сорауга юк җавап.
Уйлар белән яшәү
Гүя мең-мең савап...

Кемдер җитми җанга...
Акыл, йөрәк тоя.
Ә зиратта тагын
Чыршы ылыс коя.

*2006*

* * *

Кыш та килә көттереп,
Үзәктән өшеттереп.
Ә мин күңелне күптән
Куйдым язларга төреп.

*2006*

* * *

Син – гүзәл күчмә кош,
Кал инде, күчмә, кош...
Тышта бит салкын кыш...
Син – минем асыл кош...

*2006*

* * *

Шәһәрнең шавына
Күнегәм димен дә...
Авылга ашкынам
Айга бер – кимендә.

*2007*

* * *

Төн кап-кара, Малевичның
квадраты кебек...

Ятам... Аста балалыкның
караваты кебек...

*2007*

* * *

Рәхмәт, дөнья,
Язмышның син миңа
Тоташ шигырьлесен сайладың, –
Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Һәм өздереп елан сайрады!..

*Зөлфәт*

Кочагыма бөтен дөнья сыйган,
Күңелемә сыйган Җир шары.
Биек күге шундый зәңгәр аның,
Ә кояшы аның сап-сары.

Гаҗәп матур, шундый изге дөнья,
Керле җаның белән үрелмә!
Һәрбер сере, һәрбер могҗизасы,
Һәр бөҗәге якын күңелгә...

Үзәннәрдә күлләр тирән-тирән,
Шомландырган куе урманы.
Күңелләрне кыбырсыта торган
Һәм үзенә тарта торганы.

Күңелемә бөтен дөнья сыйган,
Нинди матур, нинди гүзәл ул!..
Төнге күктән миңа карап торган
Нинди якты, нурлы күзләр ул?..

Былбылы да, еланы да якын,
Йөгереп бар әйдә, коч аны!.. –
Бар хәятны үзенә кабул иткән
Күңелемнең кайнар кочагы.

*2007*

* * *

Эх, бермәл рәхәтләндереп
Шигырь язасы килә!
Кәгазь буйлап каләмемне
Шыгырдатасы килә!

Эссе көнне сискәндереп,
Яңгырын яудырасы,
Йә булмаса кар көртләрен
Челләгә аударасы!..

Нәни генә күлләвекне,
Эх, дулкынландырасы...
Эсседән туң йөрәкләрне
Ялкында яндырасы!..

Барлык кайгы-борчуларны

Иделдә агызасы,
Моңсу көннең уртасына
Шаян нур тамызасы!..

...Эх, бермәл талгын вакытны
Бер тизләтәсе килә,
Бар дөньясын каләм белән
Мең үзгәртәсе килә!
Мең үзгәртәсе килә!..

*2007*

* * *

Борылам да карыйм үткәннәргә, –
Нәрсә калган, дисең, нәрсә калган?..
Кемдер анда мине талбишектән
Җылы, назлы кулларына алган.

Борылам да карыйм үткәннәргә, –
Нәни малай уй-йокыга талган.
Яфрак кадәр генә учларына
Йолдыз нурын, ай яктысын салган.

Борылам да карыйм үткәннәргә, –
Үсмер малай чаба урамнардан.
Әле генә җәйгән ташлы комнан,
Әле генә яуган ап-ак кардан...

Борылам да карыйм үткәннәргә, –
Егет бара серле томаннардан...
Аңа карап, юлның чатларында
Җылы куллар яулык болгап калган.

Борылам да карыйм үткәннәргә, –
Ә үткәннәр уй-йокыга талган.
Чабып барам яңа яуган кардан –
Нидер калган анда, кемдер калган...

*2007*

* * *

Җанымда җылы –
бер уч,
Йөрәгем – кызган
корыч,
Каләмем – кызыл
борыч.

Кемгә яный куркыныч? –
Мин үзем гаҗәп тыныч!..

*2008*

* * *

Мин кояшка якын,
Ул бит минем адаш!
Нурлар ташкынында,
Әйдә, син дә адаш!

Яктылыкта йөзәм –
Нурлар елгасында.
Бермәл көләрсең дә,
Бермәл еларсың да...

Җанны җилкендерә
Нурлар шарлавыгы.
Күңелемдә минем
Нурның яңгыравыгы.

*2008*

* * *

Шигырьләрем шыгыр-шыгырдый
Арба тәгәрмәче шикелле...
Ә мин барам арбам өстендә
Читек кигән мәче шикелле.

Шигырьләрем шыгыр-шыгырдый
Ябылалмый калган капкадай.
Горур торам шушы капкада
Шомартылган каен тактадай.

Шигырьләрем шыгыр-шыгырдый
Җил шаулаткан имән шикелле.
Беркайчан да давыл иркенә
Мин башымны имәм шикелле...

Шигырьләрем шыгыр-шыгырдый...
Ә урамда яңгыр шыбырдый...

*2008*

* * *

Тәрәз төбемдә – каеннар,
Серләшәләр үзара.
Алар гына бу дөньяга,
Яшәешкә түзала.

Алар гына кайгыларны,
Сагышларны күтәрә.
Барысын да сары кунган
Башларыннан үткәрә.

Каеннардагы чыдамлык
Ис китеп, таң калырлык!..
Аналарда гына бардыр
Тагын шундый сабырлык...

*2008*

КӨЗ. КАЗАНСУ*

*(җыр)*

Казансу нигә шулай моңлана?
Казансу буйлап талгын моң ага...
Шәһәр өстеннән көзге җил уза,
Аяк астында сап-сары
Яфраклар туза.

Кушымта:

Көзләр җиткәнен сизәме ул да?..
Моңлана күңел, моңлана елга.

Казансу нигә шулай моңлана?.. –
Казансу буйлап гомерләр ага...
Соры болытлар кай якка йөзә?..
Көзләр җитүе үзәкне
Өзепме өзә.

Кушымта:

Көзләр җиткәнен сизәме ул да?..
Моңлана күңел, моңлана дөнья.

*2009*

* * *

Соң да түгел, түгел иртә дә,
Вакыты да түгел...
Тик өзелерлек булып
Тартыла күңел.
Күңел – тартылган кыл,
Ул кыл тимер кебек каты,
Кылыч кебек үткен...
Бер ишекне шакы,
Меңне шакы. Табылырмы
Сине аңлаучылар?..
Сәләтеңне, белемеңне,
Талантыңны санлаучылар?..
Юк. Мин ышанмыйм.
Өметемне кисәм аркылы.
Өметнең дә бар бит,
Бар кылы...
Соңгы кылы – соңгы ышанычым
Бу дөньяның һәр адәменә.
Көтә-көтә, чираттагы шәмем
Сеңеп бетте еллар шәмдәленә.

Соң да түгел, түгел иртә дә,
Вакыты да түгел...
Күпме теләнә аласың,
Әйт, әй күңел?!
Аңлыйм, синдә юк бит
Бер тамчы да кер һәм начарлык...
Күңелләрдә бөреләнә гайрәт,
Ишекләрне тибеп ачарлык!..

*2010*

АЛМАН ДӘФТӘРЕННӘН

*(цикл)*

* * *

Сынаулар һәм сыналулар елы,
Бүлү, кушу һәм алулар елы,
Югалтулар, югалулар елы,
Изелүләр, туналулар елы...

Ә күңелләр әле шундый җылы,
Ә йөрәкләр әле шундый олы.
Кайда кертер тайгак тарих юлы?.. –
Сынаулар һәм сыналулар елы...

Ә үткәннәр кан-яшь белән тулы,
Баш күтәрү, әрләш белән тулы.
Ничек кайтарырга югалтуны?.. –
Сынаулар һәм сыналулар елы...

Кайчан китәр туң салулар елы,
Кайчан килер тын алулар елы?..
Ә йөрәкләр әле һаман җылы –
Сынаулар һәм сыналулар елы...

*2006*

*ГЕРМАНИЯДӘ...*

Монда бүтән тормыш,
Монда бүтән яшәү.
Урамына чык та
Кешеләргә дәш...
                – Әү?..

Барысы да гади,
Бөтенесе әйбәт.
Беркем тотмый сине
Муеныңнан бәйләп.

Һәм телеңнән тотып,
Беркем йөртми сине.
Ә киләчәк тормыш
Бик селкетми сине.

Барысы да тыныч,
Ага агымсудай.
Бу алманнар шундый
Башлы халык бугай.

Әкияттәге кебек
Йортлар, бакчалары.
Кесәләрдә йөрми

«Тиен» акчалары.

Миллионнар белән
Хыялланмый халык.
(Без җигелеп үскән,
Ә тагарак – ярык.)
Барысы да чиста,
Бөтен җирдә кадер.
Алман һәр кешегә
Булышырга әзер.

Әнә, сора гына,
Тот та эндәш син...
– Әү!..
Монда бүтән тормыш
Һәм кешечә яшәү.

*2006*

*ИХ!..*

Илһам бирми алман һавасы,
Яңгыр булып килә явасы!
Үзебезчә, коеп, чиләкләп,
Кызарырлык итеп җиләкләр.

Оныттырып кайгы, шау-шуны,
Хәтерләтеп язгы ташуны,
Назлап иген тулы басуны,
Кузгатырлык итеп ярсуны.

Яңгыр булып килә явасы,
Диңгез булып җиргә авасы...
Илһам бирми алман һавасы.

*2006*

* * *

Күзләр килә томырылып,
Сары яфракка басып.
Ә күңелем ышыгында
Ямьле яз тора качып.

*2006*

*САЛЫМ ҖЫЮЧЫЛАРГА МӨРӘҖӘГАТЬ*

Урамда койма юк,
Язарга тема юк...

*Гамил Афзал*

Тагарга төймә юк,
Йөзәргә көймә юк.
Урамда койма юк,
Язарга тема юк.

Уйларың чабышса,
Беркайчан тыйма, юк!
Кияргә пима юк,
Язарга тема юк.

«Коймагыз, темагыз,
Көймәгез, төймәгез!» –
«Бернием юк, дуслар,
Сез миңа тимәгез».

*2006*

*ЮКСЫНАМ*

Ераграк киткән саен
Сине ныграк сагынам.
Син – йолдызым, кояш, аем,
Уйларыма кагылам.

Уйның очы-кырые юк,
Син генә якын аңа.
Шуңа микән, көн-таң атса,
Йөрәгем ялкынлана.

Аралар – меңәр чакрымнар,
Аралар гел юк сыман.
Еракарак киткән саен,
Сине ныграк юксынам.
*2006*

* * *

Уйларның уйнар мәле,
Җанымны кыйнар мәле.
Фикерне җыйнар вакыт,
Бирелеп уйлар вакыт.

Үткәннәр – үтелгәннәр,
Беткәннәр – сүтелгәннәр,
Утларга өтелгәннәр...
Уң булсын көтелгәннәр!

Уйларның кайнар мәле,
Киләчәк сайлар мәле.
Кояш һәм айлар мәле,
Ялкынлы тайлар мәле.
Елга-елга кан аккан
Каерылган канаттан.
Еллар саен аң арткан,
Халык хәтер яңарткан.

Уйларны җыйнар вакыт,
Югыйсә сынар вакыт.
Калыр тик сыңар мизгел,
Бер, ике... тынар мизгел.

Искә алыйк кемлекне,
Кемнәр кискән кендекне!
Ботакка өелдекме,
Кискәнгә сөендекме?

Уйларның очар мәле,
Милләтне кочар мәле.
Йөгәнне учлар вакыт,
Уйларны очлар вакыт.

Без алга йөгердекме?
Әллә соң... бирелдекме?
Искә алыйк кемлекне,
Кемнәр кискән кендекне!

Уйларның уйнар мәле,
Һәр җанны кыйнар мәле!

*2006*

* * *

Шап-шоп алма коела
җилдә.
Тайлар басып киләмени
җиргә.
Күңелемдә артта калган
кешнәү.
Нишләтәсең, шушы инде
яшәү!..

*2006*

*РӘССАМ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ*

– Кызыл алма ашыйсыңмы?
Әллә шушы алмаларга
Карап, башың кашыйсыңмы?..

– Юк, ашамыйм, калдырам...
Мин аларны полотномда
Мәңгелектә яндырам!..

*2006*

*ИМӘННӘР... ИМӘННӘРЕ...*

Юк, башларын имәгәннәр
Алман имәннәре.
Шушы микән көчле, горур
Халык дигәннәре?..

Адым саен, һәр чат саен
Имән агачлары.

Кайгы, сагыш, борчу белән
Катмаган башлары.

Бар дөньяны кочып алган
Юан ботаклары.
Үзе эре, үзе яшел
Имән яфраклары.

Иркен сулап, көлеп тора
Алман имәннәре.
Юк аларның дилбегәсе,
Тәртә, йөгәннәре...

Шуңа микән яфрак саен
Бишәр чикләвеге.
Унау, унбиш... Монда – яшәү,
Түгел чикләү иле.

Болытларга тиеп тора
Алман имәннәре! –
Бездә генә имәннәрнең
Башын игәннәре.

*2006*

*ОЯТ!*

Көзе дә көләч җәй кебек,
Карап торырга оят.
Соры күзләр, кара күзләр,
Күреп торам, монда – ят.

Казанда яңгырлы, диләр,
Беренче кар көтәләр.
Монда һаман яшел яфрак,
Җәйге җылы шелтәләр.

Монда әле былбыл сайрый,
Сандугачлар җыр суза.
Бездә күптән карга шавы
Маңгайгамы сыр суза?

Монда яңгыр – яңгыр түгел,
Җилен йокыдан уят!..
Көзе моңлы җыр шикелле,
Сүз катарга да оят!..

*2006*

* * *

Имән.
Чикләвекләр коела.
Әбиләр һәм бабайларга
Үткәннәр кайткан күк тоела.

Имән...
*2006*
* * *

Spaeter oder frueher
Alles ist vorbei.
Die Welt wird sehr rueher –
Eins und zwei und drei...
*2006*

*SCHREIB MIR...*

Schreib
mir einen
lustigen, warmen Brief.
Ich bin erkaeltet heute.
Warum warten immer
auf etwas
Leute?..

Ich
bin erkaeltet.
Es ist genau.
Was ist mit mir?..
Ich weiss nicht,
schreibe etwas
dir...

Was
ist los?..
Ich bin von
fremder Traurigkeite eine Beute...
Schreib mir...
Ich bin erkaeltet
heute.
*2006*

*АЛМАНИЯ*

Алмания,
Алман теле
Альп тауларымыни?..
Һәр көн саен күңелемдә
Рейн шауларымыни?..
И гүзәл
Алмания!..

Алмания,
Алман теле
Кельн соборымыни?..
Һәрбер шәһәр, һәрбер урам
Тарих амбарымыни?..
И гүзәл
Алмания!..

Алмания,
Алман теле
Юкәлеураммыни?..
Гете, Шиллер йөргән юлда
Уйланып тораммыни?..
И гүзәл
Алмания!..

Алмания,
Алман теле
Бахның көйләремени?..
Күңелем дә, Гейне кебек,
Моңнар көйләдемени?..
И гүзәл
Алмания!..
Алмания,
Алман теле
Альп тауларымыни?..
Бар уемны сөю кебек
Шаулап яуладымыни?..
И гүзәл
Алмания!..
*2006*

### *ЧУАГЫ...*

Әбиләр
чуагы микән?..
Ак бабай чуагымы?..
Җылы кояшта бит юа
(Шук кояш юадырмы?..)
аклыкка чумган
әбиләр...
*2006*

### *КӨЗЛӘР...*

Көзләр...
Яфрак коела
сары нур яктысында,
ә җәйләр акты шунда...
Көзләр.

Җәйләр
очып киттеләр
кыр казы канатында,
тын күкнең ак атында.
Җәйләр...

Ялгыз
яфрак атына

ак каенның очында.
Сары гөл бар учымда.
Күзләр...

*2006*

*СӨЙЛӘ ӘЛЕ...*

Нигә соң син моңсу,
Нигә соң син боек?..
Сорыйм әле синнән,
Бар көчемне җыеп.

Әллә берәр нәрсә
Булдымы соң, бәгырь?
Әллә күңелкәең
Тулдымы соң, бәгырь?

Сөйлә инде миңа,
Мин өзелеп көтәм.
Җанда тынычлык юк
Көндез, кичен, иртән.

Тик утырам әле,
Уйдан сагыш коеп.
Сөйлә әле барын,
Бар көчеңне җыеп...

*2006*

*АККАН СУЛАР, ИСКӘН ҖИЛЛӘР...*

Аккан сулар, искән җилләр –
Барысы да үтәр, җилләр.
Биләр-кала җилләгән күк,
Бүгенгегә килмәгән күк.

Шайтан кала – бер манара,
Бер Казан гына яңара.
Ашлы, Кашан җиргә сеңгән,
Болгар сере җилгә сеңгән...

Татарның бай мирасларын
Үз иттеме җир аслары?..
Алдымы соң аккан сулар,
Юк иттеме эзсез еллар?..

Алтын да юк, көмеш тә юк,
Безгә тигән өлеш тә юк.
Ун гасырлык китаплар да... –
Бер кул җитә хисапларга.

Кем сәүдәгәр, кем соң мулла –
Үткәннәрне күктән юлла.

Кем кардәше Кол Галинең?..
Әйт, җавап бир, коллар иле!..

Кем оныгы Гәрәйләрнең?..
Үткәннәрне мең әйләндем.
Алтын Урда варислары –
Килә Нейла, Борислары...
Җилләр генә җирдә елый
Үкси-үкси, улый-улый:
«Аккан сулар, искән җилләр –
Барысы да үтәр, җилләр...»

*2006*

* * *

*Газинур Моратка*

Әниеңне югалткансың икән,
И, җан дустым, нык бул, елама.
Тормыш шушы –
                        мең әйләнә бүген,
Иртәгә ул мең кат болгана...

Беләм, аңлыйм, әтиең дә мәрхүм,
Әниең дә... аның янында.
Ятимлекнең ачы биләвендә
Абынма син, дустым, абынма!..

Мең табулар, югалтулар аша
Уза һәркем,
            уза гомер дә...
Кайгыларга, сагышларга батып,
Упкыннарга берүк йөгермә!..

Нык бул, дустым, ела бүген, әйдә,
Ана куйнындагы бала күк...
Җиңеләер хәлең,
                      аязытыр
Күңел өстендәге кара күк...
Алда еллар...
                Алда озын юллар...
Ак кәгазьгә сеңгән караң күк.
Шигырь яздым сине юатырга,
Йөрәктәге тирән яраң күк...

*2006*

*КӨЗГЕ ЯҢГЫР*

Яңгыр ява,
Көзге яңгыр.
Җирдә ята
Көзге – яңгыр.

Җәй буена
Түзде яңгыр.
Түземлеген
Өзде яңгыр.

Сезме яңгыр?
Безме яңгыр?
Әллә нинди
Көзле яңгыр.

*2006*

# Чын дөресен әйткәндә...

СИНЕҢ ӨЛЕШ, МИНЕМ ӨЛЕШ…

Колхоз беркөн печән бирде,
«Чабып өй», – дип, өйгә килде.
«Минем өлеш – синең өлеш,
Тизрәк, дустым, эшкә кереш!
Килеп чыкса таныш-белеш,
Коры калуың бар», – диде.

…Эшем бетте. Ике кибән
Тора хәзер… Каһәр килгән!.. –
Колхоз әйтә: «Минем өлеш,
Җир – минеке, минем көмеш!
Берсен, давай, безгә сөйрә.
Килеп чыкса олы түрә,
Кирәгемне бирер минем.
Берсе тәк тә сиңа», – диде.

…Алып кайттым парсыз кибән…
Колхоз тагын миңа килгән.
(Туймаса да туймый, бирән!):
«Минем өлеш, давай кереш!
Килеп чыкты таныш-белеш,
Печән кирәк – синең кибән…»

*2001*

ТАТЛЫ ХЫЯЛ

Казан дәүләт университеты татар филологиясе һәм тарихы факультетының 1135 нче төркемендә сигез кыз гына укый.

Булсын иде, хет, бер малай,
Артык озын да түгел,
Артык бозылган түгел...

Күзлеген дә кисә кисен,
Тәмәкесен дә тартсын,
Безне генә яратсын...

Дәрескә дә йөргәләсен

Ара-тирәли генә,
Булсын, хет, «бәби» генә...

Укуы да булса булсын
Уртача, таман гына,
Йөрсен сау-аман гына...

Яратыр идек без аны,
Хәтта ямьсез булса да,
Хәтта гамьсез булса да,
Тәмле тәмсез булса да...

«Өф»ләп кенә йөртер идек,
Бик сүзчән булмаса да,
Бик эшчән булмаса да...

Юаш һәм җебек булсын,
Безнең төркемебездә, хет,
Бер бөртек егет булсын!..
*2004*
* * *
Кояшта көз елмаюы,
Яфраклар сары-сары...
Тавык төшенә керә, ди,
Һаман шытмаган тары.
*2005*

ШИГЫРЬ УКЫГАНДА...

*(Тулай торак бүлмәсендәге уйлану)*

Кер дә юылмады,
Юылмады ыштан.
Шигырь укынырга
Миңа кем соң кушкан?..

Ашалмады аш та,
Пары бетте чәйнең.
Әле якты иде,
Уты сүнде җәйнең.

Шигырь арасыннан
Үзең моңлы көй тап!..
Язылмады берни,
Укылмады китап.

Кайгы-сагышлары
Җанны чукыганда,
Йөрәк ярсып типте,
Шигырь укыганда...
Бөтенесе йоклый.
Җанны төнгә салдым...
Тик ятып калганчы,
Мең кат атып калдым.

Кырылды да калды

Кырык якта эшем.
Бу шигырьне яздым,
Эчем пошкан өчен.

*2005*

## ЗАМАНА БАЛАЛАРЫНА

Үзенең көен көйләтә,
Чеби тавыкны өйрәтә
Болганчык заманнарда.
Шпоркага каеш кирәк,
Ачулану сирәк-мирәк –
Һаваны таманларга.

*2005*

## СУЫ БЕТКӘН

Яза-яза, аза-аза,
Күп әсәр туып беткән.
Яңасы да чыгар иде,
Багажда суы беткән.

*2005*

## ЧЫН ДӨРЕСЕН ӘЙТКӘНДӘ...

Очтык без Марска да,
Чыктык без ярышка да,
Тетрәтеп бар дөньяны –
Көньягын һәм төньягын.

Без гел алга барабыз,
Полюста боз ярабыз –
Антарктидадан тарттырып,
Океан суын арттырып,

Бөек эш майтарабыз –
Киткәнне кайтарабыз...
Кисәбез урманын да,
Өябез курганын да...

Су астында йөрибез,
Кызыл икра күрибез...
Юпитерга очар идек,
Түзәбез лә юри без.

Безне хәзер таныйлар,
Алдамыйлар, санлыйлар.
Шундый зур безнең ярыш –
Көн саен алга барыш.

Артык кирәкми безгә,
Алдынгы илебезгә.
Гел читкә чыгартабыз,
Чыгарып, югалтабыз.

Һәрвакыт арттырабыз,
Тауларны тарттырабыз.
Берәрсе законны бозса,
Тәртип урнаштырабыз...

...Чын дөресен әйткәндә,
Үпкәли күрмә, бәндә:
Торабыз борчак атып,
Мич башларында ятып.

*2005*

## ВИРУСМЫ КҮЧКӘН?..

Эч поштырып һәм очтырып
Яннарымда йөрмәле...
Бер соравыма җавап бир,
Ник күзләрең сөрмәле?..

Тукта әле, тукта инде,
Сөйләмәм юк-бар, ялган...
Бер соравыма җавап бир,
Ник иренең буялган?..

Кичә генә саргылт иде,
Вакытмы бик тиз бара?..
Үзем дә аптырап йөрим,
Ник чәчләрең кап-кара?..

Кофтаң көннән-көн кыскара,
Кендек елмаеп тора...
Киемеңне еш юасың,
Шуңа мәллә утыра?..
Иртә белән кыска иде,
Тырнагың бик тиз үскән...
Әллә сиңа ашламалы,
Кыйммәт түгел, ташламалы
Берәр вирусмы күчкән?..

*2006*

## ҺӘР АЙ САЕН БӘЙРӘМ...

Һәр ай саен бәйрәм,
Атна саен бәйрәм.
Дус-ишләрем, котлап,
Колачларын җәйгән.

Тоташ яллар китә,
Рәттән йөзләп котлау.
Нишләтәсең инде –
Ашау, эчү, йоклау.

Эшкә вакыт та юк,
Рәхәт икән эшсез...
Кайтып кереп булмый
Өйгә төнге өчсез...

Хезмәт көне бара,
Акча килеп тора...
Күңел изрәп, оеп
Рәхәт чигеп тора.
Көн дә өстәл көйләп
Үтә гомер, үтә.
Ә иртәгә бераз
Эшләп алу көтә.

Тик чыгасы килми,
Бәйрәмнәрне өзеп.
Ярты елга алдан
Куйдым план төзеп...

Дуслар ишек кага,
Кучтәнәчләр – өем...
Һәркем көйләп йөри
Бүген бәйрәм көен...

Көн саен ял көтеп,
Ычкынабыз бәйдән...
Һәр ай саен бәйрәм,
Атна саен бәйрәм...

*2006*

## БЕРӘҮГӘ

Син йоклыйсың, тормыш бара,
Гомерләр үтә, дустым...
Кояш өйләдә,
син тагын
Юрган астына постың.

*2006*

## САТАШУ

Күпме ярлар сөелмичә калды,
Калды, әйе, үбелмичә дә.
Юкса күктән йолдыз өзеп бирер
Чаклар иде – үрелмичә дә.

*Газинур Морат*

Сөелмичә калган ярлар хәзер
Төшләремә кереп йөдәтә.
Балконнарга, перроннарга басып,
Ярсу җанны мең кат көйрәтә.

Кул болгыйлар алар, чакыралар,

Ничек итеп бармый ятасың?!
Мең мәртәбә төзәтергә булдым
Яшьлегемнең ачы хатасын.

Һәр көн саен берсен үбеп алам,
Ялганламыйм, әйе, кочам да.
Күккә менеп, йолдыз өзеп йөрим –
Җирдә йөзләп, меңләп уч анда.

Һәрберсенә салам берәр йолдыз,
Мин хан хәзер, сөеп юаныйм...
Дөнья үзе атлый, алга бара,
Сараемда кызлар куам мин.

Шундый чибәр, каһәр төшкерләре...
Төннәр буе шулай саташам.
Күзне ачсам, кызлар дигән булып,
Хатынымны кочып маташам.

*2006*

## БУТАЛЫШ

Җитми мәллә яктылык? –
Кемдер җиргә абынды.
Шырпы сыздым офыкка, –
Кояш кабынды.

*Ләбиб Лерон*

Ярканат кергәнме өйгә? –
Кемдер канат кагынды.
Шырпы сыздым төнгә карап, –
Шәмем кабынды.

Кемдер кыштыр-кыштыр килә,
Карыйм тирә-ягымны.
Шырпы сыздым газ исенә –
Плитәм кабынды.

Каракларны, баскыннармы? –
Кемдер җиргә абынды!..
Шырпы сыздым, тагын сыздым –
Лампам кабынды.

Атып бәрдем бер почмакка
Кысыр шырпы кабымны.
Кемдер табылды дигәндә,
Ут та кабынды...

*2006*

## «КЫ»ЛАШУ...

*Туган авылына кайткач, Рифат Сәлах чормада утырырга ярата.*

**К**арават, «**К**азан утлары»...
Мин ялгызым чормада.

**К**өннәр буе уйлап ятам,
Уема хис чорнала.

**К**арыйм нәни тәрәзәдән –
Тышта **к**ояш **к**ыздыра...
**К**ондиционер **к**ирәкми,
Җитә чибәр **к**ыз гына.

Саф мәхәббәт **к**өтеп ятам,
Ләкин ул әллә **к**ая.
Әллә **к**илә, әллә **к**итә,
Әллә юри **к**ылтая.

**К**улда **к**аләм, алда **к**әгазь,
Хыялда – чибәр **к**ызый...
Төнне **к**өтәм... Буш **к**арават...
«**К**азан утлары»... **К**ызу...

*2006*

АЧЫК КҮҢЕЛ...

Күңелемне ачкан идем берчак –
Амбармыни!.. Бөтен җирдә борчак!..
Гүя күңел – ашлык тулы корсак...

Күңелемне ачкан идем берчак –
Болынмыни!.. Гөлләр кочак-кочак!..
Гүя күңел – чәчәк аткан учак...

Күңелемне ачкан идем беркөн –
Каламыни!.. Халык төркем-төркем!..
Ләкин таныш түгел анда беркем...

Күңелемне ачкан идем беркөн –
Мунчамыни!.. Бөтен җирдә төтен!..
Кемдер юып ята кара этен...

...Күңеленне ачу-ябу – кулай.
Кинәт кенә уйга калдым шулай –
Минем күңел «проходной двор» бугай...

*2005 – 2006*

«СТУДЕД» СҮЗЕ...

– Студентлыкка багышлыйм:
Бер ай идән юасың!
Өч ай ашарга пешерсәң,
Студент булып туасың!..

*2006*

ИЛҺАМЛАНГАН МӘЛДӘ...

Каләмем – тырнак очы...

*Ләбиб Лерон*

Шигырь язам дигән булып,
Күпме кәгазь тырнадым.
Кәгазь – бушка, каләм – бушка,
Җәлләп-нитеп тормадым.

Үзем тырныйм, үзем мырлыйм,
Мыекны сыйпап куям.
Шигырь миңа тоттырмый шул,
Шигырь ул – җитез куян.

Үзем тырныйм, үзем сырлыйм...
Төн җиткән. Яна чыра.
Күпме генә тырнасам да,
Гел пародия чыга...

*2006*

КАЯ ЮККА ЧЫКТЫҢ?..

Мәхәббәтем төсе итеп сиңа
Бүләк итмим бәллүр ваза да...

*Рифат Сәлах*

Мәхәббәтем төсе итеп
Бүләк итмим берни дә.
Акыллылар бу заманда
Бүләк эзләп йөрми лә...

Ваза, алтын эзләр идем,
Нишләтәсең, юк чара.
Анысы да, монысы да
Терәлә бит акчага...

Чәчәген дә алыр идем,
Кыйбат икән, чукынган.
Иң яхшысы – мамык өзәм
Урамдагы тупылдан...

...Мәхәббәтем төсе итеп
Йөрәгемне биримме?..
Кая юкка чыктың, җаным?..
Сине көтәм, кил инде!..

*2006*

СЕССИЯ

Семестр буе укымый
йөргән идек,

Дискәтүкләр саен биеп,
көлгән идек.
Йокы туйган, тамак та тук,
рәхәт иде,
Тынычлыкны бозып, янга
сынау килде.

Зачетлар һәм имтиханнар
өем-өем,
Укылмаган китапларга
карап көен...
Һәрбер фәннән «дүртле» кирәк,
«бишле» кирәк,
Арлы-бирле бәргәләнә
күндәм йөрәк.

Күзләр тонган, тамаклар ач –
мәхшәр инде!..
Ярты көндә ярты еллык
белем килде.
Хәзер дискәтүкләр белән
ерак ара –
Ә син менә имтиханда
биеп кара!

*2006*

## МИН

Әле бер хаким булам мин,
Әле бер хәким булам.
Йә тәхеткә күтәреләм,
Йә дәрвиш – фәкыйрь булам.

*Рафис Корбан*

Әле зур шагыйрь булам мин,
Әле зур шаһ-ир булам.
Чиста җанлы һәм инсафлы,
Мөлаем ак ир булам.

Әле пьеса язам мин,
Әле мөхәррир булам.
Ут уйнаткан, лашман тарткан,
Кыю, зәһәр ир булам.

Әле министр булам мин,
Болытка тия башым.
Әле президент булам да
Олы башымны кашыйм...

Кыяфәтне үзгәртерлек
Илһам килеп торганда,
Берегез дә җитә алмый

Шагыйрь Рафис Корбанга!..

*2006*

КЫТАЙЛАРГА МӘДХИЯ

Бөтен тәнем буйлап ага
Кытай каны,
Чөнки сөям сары тәнле
Кытайканы.

Дөреслеккә күзең йомма,
Әйдә таны, –
Озакламый хатынлыкка
Алам аны.

Киләчәктә йөреп булмас,
Кызлар кочып.
Татарның да, кытайның да
Күзе кысык.

Кытайлар күп, алар белән
Дөнья тулсын!
Мең яшәсен кытай халкы –
Кытай тусын!..

*2006*

ЕЛАТМА...

Елатма, елатма, зинһар, –
Мин – җебегән, мин – хисчән.
Күңелләрем әллә нишли,
Кинәт кабынып китсәң.

Яшь дәрьясы ташып чыга.
Язмы? – Гөрләвек ага.
Хәятта моңсулык кына –
Мин йөзәм шул елгада.

Моңайтма, моңайтма, зинһар, –
Мин – сабырсыз, беркатлы...
Күңелләрем әллә нишли,
Әллә нишли шул чакны...

...Яшем түгеп һәм моңаеп,
Күпме гомер узылды.
Берәрегез сүндерегез
Минем телевизорны!..

*2004 – 2007*

БУР МӘЧЕ ТУРЫНДА ӘКИЯТ

Яшәгән, ди, зур мәче,
Үзе булган бур мәче.

Хуҗалары юк чакта,
Тамаклары тук чакта

Өстәлгә үрмәләгән,
Тузанны өргәләгән.

Һәм колагын тырпайткан:
Ул-бу юкмы?.. –
                    «Байтактан

Татыган юк маен да,
Килеп чыкмый җае да...

Казылыкны күрмәгәнгә,
Татлы тәмен белмәгәнгә

Бер ай тирәсе булыр.
Эләктерәсе булыр

Сырны да күбрәк итеп,
Олы бер төргәк итеп...»

Шулай уйлаган мәче,
Ашап туймаган мәче.

Чөмергән ул сөтен дә,
Сыпырткан ул итен дә.
Дөнья һаман тар булган,
Корсагы зур шар булган.

Менә шундый зу-у-ур мәче!..
Менә шундый бу-у-ур мәче!..

Өстәлдән төшәлмәгән.
Әрәмгә калган каймакны
Мескенкәй эчәлмәгән...

Хуҗалар кайткач,
                    моңа
Каты эләккән. Шуңа
Тышта куна зур мәче.
Бер тамагын тыялмыйча,
Булды бит ул хур мәче.

*2007*

* * *

Сук син, кыйна, камчыла –
Баш эшләми тамчы да
Кичәге бәйрәмнән соң,
Бер шешә әйрәннән соң...

Бер шешә кымыздан соң,
Андагы тыз-быздан соң,
Нәрсә уйлый алсын баш?!
Минем башым бүген таш.

Калганын язып тормыйм,
Язарга базып тормыйм.
Камчыласаң камчыла,
Шешә төбендә калмаган
Сыңар бөртек тамчы да!

*2008*

ТӨШЛӘНҮ

Миңа егерме алты,
Куегыз ике ярты!
Кара икра – кабымлык,
Туган көнгә калым нык!

Премия – кесәдә,
Кемнәр генә килсә дә,
Кабул итәм барысын –
Биеп-җырлап арысын!

Мин сүз әйтәм: әйдәгез,
Сүзне сүзгә бәйләгез!
Тотыгыз, күтәрегез,
Зыңлатыгыз, бәрегез!..

Шаулашыйк та гөрләшик,
Сөйләшик-чөкердәшик.
Котлауларыгыз бик шәп,
Шулай макташып яшәп

Ятулары – сөенеч.
Әйдә күтәр, әйдә эч!..
Чыланып тора касә,
Теләкләр кесә-кесә...

«Утырам әле шәйләп,
Син бик яхшы, син әйбәт...»
«Син бик уңган, син тырыш,
Һаман да эшлә, тырыш...»
«Эх, урман буйларында,
Син генә уйларымда...
Наратлар һәм каеннар,

Уйлар өчен җаем бар!..»

...Миңа егерме алты.
Сәгать алтынчы ярты.
И сөендем, куандым... –
Бастырылып уяндым!..

*2008*

## БЕР КҮРӘСЕМ КИЛӘ...

Бер күрәсем килә синең сынны,
Күтәр әле тәрәз өлгесен.

*Рифат Сәлах*

Бер күрәсем килә синең сынны,
Күтәр әле тәрәз өлгесен.
Душтан чыккансыңмы, урангансың
Хыялымның ап-ак сөлгесен.

Бер күрәсем килә синең сынны,
Челтәрне дә эт син кырыйга.
Бик күрәсем килә, хисләр шашкан... –
Әвереләм бугай кыргыйга.

Бер күрәсем килә синең сынны,
Тәрәзәңне ач син киң итеп.
Ходай яраткан бит сине миңа,
Мине сиңа пар һәм тиң итеп.

Бер күрәсем килә синең сынны,
Хыялларым төптә – тирәндә.
Бүлмәгезгә иңсәм, теге сөлге
Шул мизгелдә ятар идәнгә...

Бер күрәсем килә синең сынны... –
Уйлар китте, ахры, читкәрәк.
Пышылдыйсың кебек пәрдәң аша:
«Иртәрәк шул әле, иртәрәк...»

*2009*

## СИН МОҢАЙМА, МӘКТӘП!

Менә безнең мәктәп, менә безнең бүлмә...

*Илнур Юнысов*

Кайсы дустым мине
Ялгыз дип әйтала? –
Менә минем хатын,
Менә минем бала!..

Узган Сабантуйда
Тагын калдым батыр! –
Менә минем «Ока»,
Менә минем фатир!

Тырышканга Ходай,
Бирәм, ди бит, ярый...
Менә минем коттедж,
Менә минем сарай!

Менә минем елга,
Менә минем урман... –
Шундый уйлар белән
Кайтып барам кырдан.

Син моңайма, мәктәп!
Безнең бүлмә якта
Торыр «И.Юнысов»
Дигән элмә такта!

*2009*

БӘХЕТСЕЗРӘК...

Өйләнешкән парлардан да
Без бу кичтә бәхетлерәк!

*Рифат Сәлах*

Өйләнешкән парлардан да
Бәхетлерәк без бу кичтә.
Тиештер ул икебезгә
Шушы кичтә керү мичкә...

Әйдә әле, югалыйк бер
Җәйге төннең карасында.
Агыйдел буена барыйк,
Куе таллар арасына.

Серләшик бер, үбешик бер...
Беркем күрмәс айдан башка.
Су буенда уйнар идек
Сикерешеп таштан ташка...

Нигә туй безнеке түгел,
Без биредә кунак кына?..
Йөрәгебез ашкынса да,
Без биибез тыйнак кына.

...Синең җылы куеныңнан
Чыга алмас идем һич тә.
Өйләнешкән парлардан, эх,
Бәхетсезрәк без бу кичтә.

*2009*

# Гасырда фасыллар БУТАЛГАН...

## КАРА-АК

Бу ике төс капма-каршы –
Кара-ак, кара-ак,
Төннең башы, көннең башы –
Кара-ак, кара-ак.

Яман-яхшы ике төрле –
Кара-ак, кара-ак,
Кем явыз, кем тәмле телле –
Кара-ак, кара-ак.

Кемнең уе кыек, туры –
Кара-ак, кара-ак,
Дошманлык һәм дуслык юлы –
Кара-ак, кара-ак.

Бу дөньяда гел янәшә –
Кара-ак, кара-ак,
Адәмне үзенә дәшә –
Кара-ак, кара-ак.

*2002*

* * *

Һәр адәм үзен кайгырта,
Бүтәнне бирми уйлап та.
Атлар гына бергә-бергә
Су эчә, ахры, улактан.

*2003*

* * *

Гомер буе «Халкым!» диеп
Янып-көеп яшә дә,
Синең исемең тирбәлер
Рәшәдә...

*2003*

## «ӘЛЛҮКИ» ГИМНЫ*

*(җыр)*

Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсе оешу уңае белән

Ниһаять!.. Ниһаять!..
Җанланды бар хәят!..
Таралды болытлар,
Балкыды офыклар.
Таң ата!.. Таң ата!..
Өметне яңарта!..
Яктылык күңелдә,

Балкышка күмелә.

Елмаеп карыйбыз
Туган һәр иртәгә.
Кояшның җылысы
Кимемәс иртәгә.

Гел шулай кыйбланы
Күрсәтеп торыр ул.
«Әллүки» – мәңгелек
Сүрелмәс җырдыр ул!

*2003*

* * *

Йөзегең алтын икән лә,
Күңелең салкын икән...

Йөрәгең алтын икән лә,
Җаныңда ялкын икән...

*2004*

ТУГАН ЯККА КАЙТА КЕШЕ...

Бик-бик авыр булганда да,
Җан чемердәп туңганда да,
Иңгә сагыш кунганда да,
Туган якка кайта кеше...

Чит тарафта йөри-йөри,
Акча, байлык күри-күри,
Туң бәгыре эри-эри,
Туган якка кайта кеше...

Башка бәла килгәндә дә,
Тездән җиргә иңгәндә дә,
Чүгеп, башын игәндә дә,
Туган якка кайта кеше...

Хыяллар алдаганда да,
Мал куып алҗыганда да,
Гомерен барлаганда да,
Туган якка кайта кеше...

Йөрәк тибә ярсып-ярсып,
Чәчләрдә кар, күзләрдә чык,
Булса да ул карт йә карчык,
Туган якка кайта кеше...

*2005*

## ГАСЫРДА ФАСЫЛЛАР БУТАЛГАН...

Гасырда фасыллар буталган,
Болганган ассорти диярсең.
Ак кышта гөрләвек акканда,
Эх, эшләр бик хөрти, диярсең.

Җәйләрдә яфраклар коелса,
Кар яуса, үз-үзен белешми...
Бу дөнья ни кылмас, ни булмас –
Күп сорау...
Аптырау килешми.

Көзләргә күзлегеп, гөл туса,
Чәчәккә төренсә ахырда.
Уйлыйсың: алтынга әйләнә
Сандалда кургаш та, бакыр да...

Гасырда фасыллар буталган,
Беләмсең, без кая барганны?!
Хыяллар тормышка яралды –
Хак итеп ясадык ялганны.

*2005*

## ЯҢА ЕЛЛАР КИЛӘ…

Яңа еллар килә, Яңа еллар!
Ә күңелдә туа яңа җырлар,
Сөенеч һәм шатлык белән тулы…
Ак кар булып бәхет суза кулын.

Кышкы җил дә күңелләргә кага,
Шаяра ул, шундый рәхәт аңа!..
Хыяллар да ашар тормышка,
Шулай кебек карап торышка.

Җан эчендә ап-ак өмет яна,
Өмет булып гүя ак кар ява…
Әкият тә чынга ялганган:
Көләч йөзләр бүген алланган…

Яңа еллар килә, Яңа еллар!
Ә маңгайга сыза яңа сырлар.
Алда туган яктылыкка таба –
Һәрбер кеше үз бәхетен таба…

*2005*

## ХАТЫН-КЫЗ...

Хатын-кыз ул – горур яңгырый,
Күңелендә хисләр яңгыры.

Йөз мең чәчәк бүләк итәрлек,
Еракларга алып китәрлек...
Хатын-кыз ул – горур яңгырый!..

Күңелендә хисләр яңгыры,
Әйтерсең ул – гүзәл таң гөле.
Төнге күктән йолдыз алырлык,
Назлы учларына салырлык...
Күңелендә хисләр яңгыры.

Йөз мең чәчәк бүләк итәрлек,
Гомерләрне көлеп үтәрлек.
Хатын-кыз ул – сөю патшасы,
Хатын-кыз ул – җәннәт бакчасы...
Йөз мең чәчәк бүләк итәрлек.

Еракларга алып китәрлек...
Эх, андагы сер һәм чибәрлек!..
Изге җаны хискә күмелгән,
Хатын-кыз ул нечкә күңелдән...
Еракларга алып китәрлек.

Хатын-кыз ул – горур яңгырый!..
Күңелендә сөю яңгыры.
Бар дөньяны бүләк итәрлек,
Ак хыялга алып китәрлек...
Хатын-кыз ул – горур яңгырый!..

*2006*

ВАКЫТ

Бу көннәрне,
Гомерләрне
Вакыт ваклый...
Вакыт төгәл...
Вакыт күмә,
Вакыт таптый.

Бер сулыш та,
Бер көлеш тә –
Ул тик ятмый.
Вакыт ага,
Вакыт таба,
Вакыт аклый...

Мең кинәнә...
Җиз инәгә
Барын саплый...
Вакыт үтә,
Вакыт көтә,
Вакыт атлый...

Изге антны...
Чын талантны
Читкә атмый.

Гөлләр өя,
Күккә чөя –
Вакыт саклый!..

*2006*

ЯШӘЕШ

Үлде кеше,
Сүнде кеше,
Язмышына
Күнде кеше...

Тоеп сөю,
Яратуны,
Таң атуга,
Бала туды...

*2006*

* * *

Язны бутап, көзге яңгыр
Явып маташа.
Саф хисләр өермәсендә
Ул да саташа.

*2006*

* * *

Кысыр җәйне кысып,
Көз килә...
Арык бал корты
«Без-з-з...» килә.

*2006*

* * *

Кара көйгән асфальт –
Газ плитәсе...
Салкын тамчы суытыр –
Ни хәл итәсе...

*2006*

* * *

Эх, бу хәзергене
Җирдән җуясы килә!..
Машиналар урынына
Тарантаслы атлар
Китереп куясы килә!..

*2006*

МАНТЫЙК

Кош-корт, маллар санын
Дәүләт чутлап йөри.
Басу уртасында
Сыер утлап йөри...

*2006*

* * *

Җәй димәссең. Суык.
Җылылыкка түләнмәгәнмени?..
Малай-шалай йөри,
Урамда җил куып...

*2006*

ИМӘНКИСКӘНЕ УЙЛАП...

Әйтәм – булмасын хата!.. –
Кояш урманнан чыга да
Чулманга кереп бата!..

*2006*

ТУРЫ...

Карават минем үлчәмгә
                    туры килми...
Шуңа бер башын алып ташларга
                            туры килде.

*2006*

ТАНЫШУ

Мотор шавы...
          Машиналар
                    чабыша.
Берсе белән берсе таныша –
Шап итеп!..

*2006*

* * *

Зәңгәр күкне ярып оча
Ак болытлар.
Кем үз бәхетен күкләрдә
Оныткан?

*2006*

* * *

Кызлар кызык эзләп йөри,
Егетләр кыз күзләп йөри...
Кызлар күзгә багалырмы?..
Егетләр кыз табалырмы?..

*2006*

* * *

Үткәннәрне онытырга кирәк,
Онытырга кирәк үткәннәрне.
Әллә инде сагыш-үпкәң бармы?..
Күккә очкан кочкан-үпкәннәрне
Кышка калган хәтер ышыгында
Җылытырга, җылытырга кирәк!..

*2006*

* * *

Каударлана-каударлана
еллар ага.
Томырылып карыйм
артыма...
Өй артында, җилләр
ышыгында,
Бала чагым таган
атына...

*2006*

* * *

Туң машина шавы,
Коры ыгы-зыгы.
Кирпеч, цемент тавы –
Кая соң тормышның
Без көткән кызыгы?..

*2006*

СЕНТЯБРЬ ИРТӘЛӘРЕ

Җәйдән искән җылы җилкәй
Битемне иркәләде.
Урамнарда әле һаман
Сентябрь иртәләре.

Яфраклар да һаман шул ук,
Шул ук ис һәм яшеллек.
Якты кояшка бер багып:
«Җәем!» – диеп дәшәрлек.

Соңгы җырлар җырланмаган,
Соңгы көй уйналмаган.
Көзгә керү баштан чыккан,
Әлегә уйланмаган.

Кошлар һаман сайрап йөри
Җәйнең матур моңнарын.
Мин тоям һәрбер үләндә,
Һәр яфракта моң барын.

Шундый рәхәт, шундый җылы
Сентябрь иртәләре...
Кояшлы яңгыр сибәли –
Күзләргә иртә әле!..

*2006*

АК КҮМГӘН САРЫЛЫК

Ак каен, ап-ак кар,
Сап-сары яфраклар...
Ап-ак йорт, ак башлык –
Дәвамлы тоташлык...

Сап-сары машина
Киләме каршыма?..
Ак буран уртасы –
Ак кәгазь ертасы...

Ап-ак күк, ак болыт...
Сап-сары ут булып
Торамы үзәге?..
Син гөлне өз әле...

Ак – сары арасы...
Сагышның сарысы,
Бәхетнең ап-агы,
Дөньяның ак чагы...

Ак каен, ап-ак кар,
Сап-сары яфраклар...

*2006*

* * *

Бөтен дөнья бозык,
Бөтен җирдә зина.
Ябырыла сиңа,
Ябырыла миңа...

Кая ихлас күңел,
Кая соң ул сафлык?
Барысы да ялган,
Барысы да сатлык...

Тормыш шундый кара,

Ә яшәеш пычрак.
Нур өстисе иде
Минутларга ешрак...

Моң кушасы иде
Усал карашларга...
Кемдер нидер эшли
Төнге шалашларда...

Кемдер нидер эчә,
Уразасын таптап.
Нигә иман чыкмый
Үзенекен яклап?..

Ник сабыйлык кунмый
Уйлар чоңгылына?..
Бозык каралыктан
Минем тын буыла...

Кояш яктырактыр,
Ул – саф, ихлас, тыйнак...
Икәү китик әле
Кояш эзе буйлап...

*2006*

* * *

Сары-сары сагыш,
Кара-кара кайгы.
Үзең кичермәсәң,
Уйлаулары җайлы.

Дөнья тыныч чакта
Күк йолдызлы, айлы.
Бәхет-сөенечтән
Күзләр якты, майлы.

Бәла сорап тормый,
Ярлымы син, баймы.
Акыллымы, юкмы,
Әллә башка «саймы».

Юккамы каенда
Ак-каралы кайры?..
Сары-сары сагыш,
Кара-кара кайгы.

*2006*

* * *

Ак каеннар шәрә-шәрә,
Ботакларын бәрә-бәрә,

Көзге җилдә бөгеләләр –
Йөрәкләре парә-парә...

Ак каеннар боек-боек,
Кайгыларын тыеп-тыеп,
Гел моңаеп торалар күк,
Күз яшьләрен коеп-коеп...

Ак каеннар серле-серле,
Ак хыяллар төрле-төрле.
Сагыш та ак булыр иде,
Тормыш кына керле... керле...

*2006*

## ЙОРТ КАЗЛАРЫ ЗАРЫ

Кыр казлары, кыр казлары,
Сез бик бәхетле казлар.
Гомер юлыгызда күпме
Җәй, көз, кыш һәм дә язлар.

Сез ирекле, киң канатлы,
Киң күңелле казлар сез.
«Кыйгак-кыйгак» тавышыгыз
Борчусыз һәм казасыз.
Безнең гомер бер җәй генә,
Сезнеке – чикләнмәгән...
Сез яшәү тәмен беләсез,
Киләткә бикләнмәгән.

Канатларыгызны киереп,
Күктән очып узасыз.
«Кыйгак-кыйгак» киләсез дә
Безне кызыктырасыз.

Сез ирекле, киң күңелле,
Бер тәкъдир йөкләнмәгән.
Гомерегез моңлы җырдай –
Мәңгелек, чикләнмәгән!..

*2006*

## АГЫМСУЛАР...

Сулар гел агар инде лә,
Үз юлын табар инде.
Күңелләргә ялкын түгел,
Агымсу кабар инде...

Дөрләр инде күңелләр дә
Салкынча сулар белән.
Су буенда басып торам

Илаһи уйлар белән...

Сулар уйчан, сулар тирән,
Сулар – сагыш, гамь генә.
Сагышларсыз яшәп булмый,
Сулар яшәүдән килә...
Сулар да агар инде лә,
Йөз ел, мең ел агарлар.
Кешеләр яшәү асылын
Суга карап табарлар...

*2006*

* * *

Күзләр кышка тоташа,
Кышлар язга тоташа... –
Сөю туңга ут ача,
Гомер шулай буташа,
Гомер шулай утлаша...

Ут белән ут арасы,
Күзләр аша барасы,
Кышлар аша барасы.
Юлның агы, карасы,
Юк анда тукталасы...

Гомер-сөю гел бергә –
Бара алар кабергә,
Буйсынмыйча әмергә,
Әйләнәләр әмиргә...
Гомер-сөю гел бергә!..

*2006*

* * *

Тәңкә-тәңкә карлар һаваларда...
Бөтерелеп кенә явалар да
Сибеләләр җиргә аклык булып
Һәм куналар җанга сафлык булып.

Җый гына, җый кайнар учларыңа...
Энҗе бөртекләрен учлармын да
Йөгерермен, белмим, кая таба?..
Әллә кояш, әллә айга таба?..

Ашыгырмын, әйе, ашкынырмын,
Йолдызларга карап баш орырмын...
Ап-ак кына гөлләр арасыннан
Ак бәхетләр генә ява сыман...

Тәңкә-тәңкә карлар һаваларда...

*2006 – 2007*

РУСИЯ

Юлларыбыз кәсле,
Ә агачлар бәсле,
Күзләребез яшьле –
Менә шундый ясле!..

*2007*

* * *

Кубарылып, тугарылып
Буран бурый,
Кара төндә килер көнне
Юрый-юрый.

Юлчыларны адаштыра
Өермәдә,
Бураннардан бәхет эзләп
Син йөрмә дә...

Ачу итеп ак кар сылый
Бөтен җиргә,
Күз ачкысыз аксыл-зәңгәр
Төтен җирдә.

Дуласын ла, бөтерелсен
Төн чагында,
Оясын сукбайларның
Кочагына...

Таң алдыннан ул барыбер
Тыначак бит.
Бит очына алсу кояш
Куначак бит...

*2007*

КАРАБАЯН

Карабаян – Теләче районындагы авыл. XVIII гасыр уртасыннан мәгълүм. 2000 елдагы мәгълүматлар буенча бирелә 47 кеше яши.

*Рәсми мәгълүматлардан*

Үткәннәрең серле синең,
Үткәннәрең тирән.
Мишә белән Нырсы аша
Сиңа кайтып киләм.

Карабаян, Карабаян,
Килеп чыктың микән каян?..

Йортларыңда сүнеп бара

Яшәү учаклары.
Күңелемне көл туздырган
Җилләр кочаклады.

Карабаян, Карабаян,
Йөрәгеңдә яра каян?..

Урамнарың тынып бара,
Сулып бара гөлләр.
Киләчәкне Ходай белсен:
Алда моңсу көннәр.

Карабаян, Карабаян,
Авырлыкка карама, ян!..

*2007*

БЕРӘҮГӘ

Үстергәч, үсенмәс,
Күпсенмәс дисәм дә...
Тау кадәр «мин» йөри
Уч кадәр кесәңдә.

*2007*

* * *

Тоташ соры пәрдә
Күкне каплап алган.
Кояш чыгар, диләр, –
Ялган, ялган, ялган!..

*2007*

* * *

Яуса яумый яңгыры да,
Тора эчне поштырып.
Соры күкнең уртасында
Болыт йөри пошкырып.

*2007*

ТӘГӘРМӘЧ...

Казан дәүләт университетына

Иярсез ат кебек чабып узды
Иң бәхетле чагы гомернең.
Мин бит синдә каткан ипи белән
Белем ташын бергә кимердем.

Салкын чәй дә булды,
кайнар чәй дә –

Авыз пеште, өреп эчмәгәч.
Ап-ак колонналар арасында
Шыгыр-шыгыр килде тәгәрмәч.

Гомер тәгәрмәче,
Яшьлек тәгәрмәче,
Студент тәгәрмәче иде ул.
Бу көннәрнең иң-иң кадерлесен,
Иң яктысын үзенә җыйды ул.

Алган белем артык күп тә түгел,
Бер чемодан икән нибары.
Миннән күпкә акыллырак, беләм,
Универның ап-ак дивары.

Җыйган белем бер чемодан гына,
Хатирәләр ничә чемодан?!
Юкка гына энҗе бөртегедәй
Сайлап-сайлап кына җыймаган.
Ленины да, Толстое да шунда,
Ап-ак колоннадан тузан да...
Синең яннан гомер тәгәрмәчен
Шыгырдатып кына узганда,

Бер дәшәрмен, елмаермын әле,
Син танырсың мине, танырсың!
Ап-ак горур колонналар белән
Күңелемә кереп калырсың!

*2007*

* * *

Мин ышанам:
бер киләчәк әле,
Бер көләчәк әле кояш та.
Шат нурларын бөркиячәк әле
Бар дөньяга, җиргә ул башта.

Кайгыларны
бер юачак әле,
Бер туачак алсу таңы да.
Болытларны ул куачак әле
Ак офыкның чиксез ярына.

Мин ышанам:
бер киләчәк әле,
Бер көләчәк әле безнең көн.
Җанга җылы бөркеләчәк әле,
Барлык җаннар булып бербөтен.
Әйе, шулай,
өметләнәм әле,

Көн бетмәгән әле безгә дә.
Кояш нурын киметмәгән әле,
Болытларны кире эзләмә!

Мин ышанам:
бер киләчәк әле,
Бер көләчәк әле язмыш та.
Бөтенесе бер күрәчәк әле,
Изрәп-оеп татлы сагышта...

*2007*

* * *

Эссе җәйнең уртасына
Көзме килеп кысылган?
Кызу көнгә салкын-салкын
Яшьләр килеп кушылган.

*2007*

* * *

Каенны
җил бөгә.
Әйтерсең
дилбегә
Таккан ул
каенга.
Уңга да
каера,
Сулга да
каера.

Яфраклар
сибелә...
Ә каен-
кай белә:
Бу язмыш
богавы –
Уңга да
болгавы,
Сулга да
болгавы...

*2007*

* * *

Гомер узып тора,
Күңел сызып тора.
Мең кат яшәр өчен
Җаным кызып тора.

*2007*

* * *

...Әлегә мин Ленарны, үзе язганча, «бөре ачкан зирек» халәтендә күрәм. Колач җәйгән зирекләрнең матур шаулавын еракларга ишеттереп, шигъриятнең авыр юлларыннан барасы да әле барасы!

*Илдар Юзеев*

«Ленар энем, мин бит белеп торам,
Мин бит күреп торам барсын да.
Нигә диеп синең җаның сыза,
Ә йөрәгең нигә ярсына...» –

Диеп эндәшәсең кебек мәңгелектән,
Зәңгәр күкнең өске катыннан.
Әйе, абый, бәхет белән бергә
Кайгы-сагышы да татылган.

Тигез түгел дөнья, дөрес түгел,
Богаулыйсы килә ялганны!
Уятасы килә милләтемне,
Уятасы – мәрткә талганны!

Әйе, абый, без бит көрәшчеләр,
Тынгысыз җан – шушы нәселдән.
Күңел генә тирән коесына
Иң самими хисне яшергән.

Күңел аша үтә барысы да,
Күңел генә түзсен, чыдасын.
Без бергәләп кабызырбыз әле
Дөреслекнең сүнмәс чырасын.
Богауласын безне, киссен, ассын –
Без ирекле әле, ирекле.
Шаулатасы иде яфрак ярган,
Уйга калган боек зирекне.

«Ленар энем, мин бит белеп торам,
Мин бит күреп торам барсын да...» –
Дисең дә син, китеп югаласың
Чиксез мәңгелекнең каршында...

Илдар абый, мин бит тоеп торам,
Мин бит сизеп торам һәммәсен.
Безнең өмет бер ачачак әле
Киләчәкнең тонык пәрдәсен!

*2007*

* * *

Шыбыр-шыбыр, шыбыр-шыбыр –
Яңгырмы?
Бар халәткә, хиссияткә
Чаңдырмы?..

Боларда дөреслек
Азрак бар.
Шыбырдый, шыбырдый... –
Яфраклар.

*2007*

* * *

1

Чалма. Чапан. Сакал.
Әллә үзе сакау?.. –
Ураныплар тунга,
Мыгырдана шунда.

2

Кулларында бокал.
Шәраб. Сало. Сакал.

*2007*

* * *

Яшьтән яшьлек йога,
Карттан картлык йога –
Менә шундый йо‡га!

*2007*

## КЕШЕ ҮТӘСЕ ЮЛ

Йөгер, чап син, ашык –
Сиңа юллар ачык.
Тормыш көтеп тора –
Кулда агач кашык.

Торма башың кашып,
Хыял чынга ачык.
Язмыш көтеп тора –
Кулда тимер кашык.

Йөгер шык-шык басып,
Төенчегең асып.
Дөнья көтеп тора –
Кулда көмеш кашык.

Соңгы сулыш – ашык!
Йөрмә син таш ташып.
Күкләр көтеп тора –
Кулда алтын кашык.

Кеше гомер буе
Тормасын баш кашып.

*2007*

* * *

Яңа еллар котлы булсын берүк,
Ап-ак бәхет яусын күкләрдән! –
Серле җиһан, могҗизалы җиһан
Шундый теләк көтә күпләрдән.

Яңа еллар котлы булсын берүк,
Яңа булып керик яңага!
Яңа елда бар да чынга аша,
Шатлык килә, өмет яңара.

Яңа еллар котлы булсын берүк,
Яратылып яшик, яратыйк!
Күңелдәге кайгы-борчуларны
Буран белән куып таратыйк!

*2007*

## ЯРЫЙ ӘЛЕ ТУГАН АВЫЛЛАР БАР

Авылыма кайтам әле, әйе,
Сагындырган икән авыллары.
Бер мизгелгә онытылып торган
Бу дөньяда әле авыл бары.

Онытылган икән... оныттырган
Таш шәһәрнең ыгы-зыгы шавы.
Әллә кайда гына китеп барган
Бала чактан калган кендек бавы.

Алны-артны, көнне-төнне белми,
Шәһәр казанында кайныйбыз без.
Ярый әле туган авыллар бар,
Шунда гына кайтып айныйбыз без...

Ярый әле туган нигезең бар,
Әнкәң көтеп торган җылы өең...
Әллә кайда югалмаган икән
Бала чакта чияләнгән төен.

Таш эченә куып кертелгән җан
Җиңеләеп кала, иркенәя.
Сабый күңел урам уртасында
Рәхәтләнеп ак канатын җәя.

Авылыма кайтам әле, әйе,

Күңелемә тансык авыл кары.
Ярый әле туган авыллар бар,
Алга дәшеп тора авыллары!
*2008*

* * *

Әллә нинди тормыш,
Әллә нинди яшәү.
Яхшырактыр, бәлкем,
Бернәрсә дә дәшмәү.

Әйе, яхшырактыр
Уйлап кына йөрү.
Берни белмәгәндәй
Уйнап кына йөрү.
Әйе, яхшырактыр
Көлеп карау, көлеп.
Тик кайчакта кирәк
Өреп карау, өреп...

Эт шикелле өрү,
Бүре кебек улау...
Бәлкем, яхшырактыр
Уйда гына уйлау.

Бары тик кар ява
Талгын, әкрен, тып-тын.
Беркем сүз әйталмый,
Кабарталмый сыртын.

Әйе, яхшырактыр
Кар хәлендә калу.
Тик дөньясы кырыс –
Бүлү, кушу, алу.

...Эх, яварга инде
Әллә яңгыр булып?!
Ерак офыкларда
Куера зур болыт.
*2008*
* * *

*Казан дәүләт университетының*
*1 нче номерлы тулай торагына*

Булмаса да тулай торак
Шәп «Болгар» номерлары,
Ким җире юк. Бик тирәндә
Аның да тамырлары.

Кемнәр генә көн итмәгән,
Кемнәр генә тормаган!..

Ә урамда җил уйнаган,
Кергән калай торбадан.

Кергән дә калай торбадан,
Бер әйләнгән чормадан...
Тулай торак бүлмәсендә
Кемнәр дөнья кормаган!

Биек-биек түшәмнәре,
Калын-калын диварлар.
Шушы баскыч буйларында
Таң котә сөйгән ярлар.

Олы тәрәзә буенда
Кемдер урам күзәтә,
Ыспай егет үткән-сүткән
Яшь кызларга күз ата.

Тормыш кайный
кухнядагы
Кайнар шулпа шикелле.
Моннан кемдер күчеп китте, –
Быел яңалар килде.

Монда яшьлек, монда үткән,
Киләчәк көннәр нуры.
Тулай торак җанга якын,
Юллары аның туры.

Күпләрнең җылы ышыгы,
Җил тидермәс түбәсе.
Тулай торак күпне күргән,
Тагын да бар күрәсе...

Ә урамда җилләр уйный,
Керә калай торбадан,
Шушы йортның хуҗасы күк
Бер әйләнә чормадан.

Коридордан, бүлмәләрдән
Чабып кына уза да...
Беразга тынып тора да
Тагын ярсып кузгала.

*2008*

* * *

Яфраклар яшел икән.
Күңелеңдә йөргән серне
Җаныңа яшер икән.

Яфраклар яшел икән.
Күк йөзендә ялт-йолт килә
Аҗаган, яшен микән?

Яфраклар яшел икән.
Җаныңның кап уртасыннан
Берәрсе дәшер микән?

Яфраклар яшел икән...
Тирән серең берәр вакыт
Бәхетме чәчер икән?..

Яфраклар яшел икән...
Сөйгән ярыңның җанына
Сереңне яшер икән!..

*2008*

* * *

Күктә болыт,
Җирдә сулар,
Һавада яңгыр.
Киче елак,
Таңга ерак,
Бу – төнге таңдыр.

Тиздән җилләр
Үләннәрне
Бер юатачак.
Тамчы-тамчы
Су эчендә
Ак төн атачак!

*2008*

* * *

Урам тулы бомж этләр, бомж кошлар,
Алар ничек төн үткәрер, ничек кышлар?

Хәер эстәп утыралар тукталышта.
Каурыйлары һәм йоннары лычма, лычма!

Кем ни бирә, риза булып йөри алар,
Әкрен генә койрыкларын сөйри алар.

Күпләр бүген күңелләрен бикләгәндер,
Мәрхәмәтле җаннар әле бетмәгәндер...

Зур йөрәкләр, киң күңелләр кая калды?..
Яшәешне салкын тынлык камап алды,
Боз катырды тәрәзләргә, кояш үтми,
Игелек йомгагын никтер беркем сүтми...

Урам тулы бомж кошлар, бомж этләр...
Кемнәргәдер якын алар, кемгә – читләр...

Һәрнәрсәгә була ахыр, була чикләр.
Болай барса, Ходай үзе Җирне бикләр!..

*2008*

* * *

Безгә кадәр яшәгәннәр,
Бездән соң да яшәрләр.
Дөнья туктаусыз картая,
Дөнья һаман яшәрә.

Пушкинны күргән наратлар*
Иелгән җиргә таба.
Ике йөз ел уен эшме? –
Вакыт чаба да чаба...

Урал тавы авыр сулый –
Ул да иңеп барамы?..
Алда билгесезлек ята,
Киләчәк кап-караңгы.

Искелеккә алмаш – яңа,
Картлыкка яшьлек атлый.
Кояш кына бу галәмдә
Никтер буын яңартмый.

Үткәннәрне себерәбез
Һәм чүплеккә түгәбез.
Җан асрарлык акчабыз бар,
Нәни генә түбәбез.

Җимерәбез... Киләчәктән
Нәрсә диеп дәшәрләр? –
Безгә кадәр яшәгәннәр,
Бездән соң да яшәрләр!..

*2008*

* * *

Бу телефон мәңге шалтырар инде,
Еллар үтәр, һава алмашыр.
Кемдер анда, үткәннәрен эзләп,
Хатирәләрендә адашыр.

Блокнотын алыр кулларына
Һәм җыяр ул шушы номерны.
(Киләчәкне ялгый вакыт җебе,
Ә үткәннәр барбер кадерле!)

Телефонны, белмим, кемдер алыр,
Таныш тавыш, әллә ят тавыш.

Күңелләрне биләр якты бәхет,
Әллә җанны басар ят сагыш?..

Бәлкем, телефонны беркем алмас,
Җавап килмәс ерак тарафтан.
Узган мизгелләрне вакыт җиле
Бер мизгелдә куып тараткан.

Бу телефон мәңге шалтырар инде,
Еллар үтәр, һава алмашыр.
Блокнотын алып кулларына,
Үткәннәрдә кемдер адашыр...

*2008*

* * *

Эшләр бар, эшләр күп –
муеннан.
Хәтердән җуелмас
җуелган.

Җитешим берсенә...
кайсына?
Күңелне тарткалый
кайсы да...

Бусы зур, бусы… юк,
кечкенә...
Эшлимме иртәдән,
кич кенә?..

Башкаем буталган
эшләрдән.
Йокламыйча күргән
төшләрдән.

Эшләнер ул эшләр
берәр мәл.
Табылыр бер әмәл,
мең әмәл.

...Эшләр бар, эшләр күп –
муеннан.
Ә алга зур максат
куелган!

*2009*

* * *

И Ходаем, мәңге бакый
Иман бир Син.
Күңелләрдә ышаныч һәм
Иман йөрсен.

Яшәешне тиңләп була

Гөлчәчәккә...
Шул ышаныч алып барсын
Киләчәккә.

Яманлыкка каршы көчне
Иман бирсен.
Иман белән бергә җанга
Шәфкать иңсен.

Кешеләрнең күңелләре
Якты булсын.
Авызлары һәм телләре
Татлы булсын.

Күзләрендә очкын булсын
Иман нуры.
Һәрберсенең юлы булсын
Дөрес, туры.

Йөрәкләрдә һәрчак йөрсен
Изге хисләр.
Бу дөньяда хөкем сөрсен
Якты төсләр...
И Ходаем, терәк бул Син
Һәммәсенә,
Фанилыкның һәрбер мохтаҗ
Бәндәсенә!

Яшәешне тиңләп була
Бер мизгелгә.
Калдырма Син колларыңны
Эзсез көлгә.

Без беләбез ялган һәм чын
Аермасын.
Иман белән ышанычтан
Аерма Син!

*2009*

БӘХЕТ ҖЫРЫ

*(җыр)*

Бәхет ул ак төстә була,
Яңа яуган кар кебек.
Күңелне яктыртып тора,
Тәүге сөйгән яр кебек.

Кушымта:

Үз бәхетең булсын үзеңә,
Бәхетеңне ташлап калдырма!
Күктә көлсен бәхет кояшы,

Бәхет кошы очсын яныңда!

Бәхет ишеге ачыла
Көтә белгән җаннарга.
Бәхет сиңа сайрап куна,
Дәшеп алсу таңнарга.

Кушымта.

«Бәхетең яр булсын» диләр –
Шулай бәхет юрыйлар.
Сөйгән ярлар, күккә карап,
Бәхет кенә сорыйлар.

Кушымта.

*2009*

* * *

Исәнме, кояшым, исәнме!
Бик күптән көтәбез, чыкмыйсың.
Ай буе болытлар артында
Йоклыйсың, ахры, син, йоклыйсың.

Халыкка син кирәк, бик кирәк,
Кояшсыз көннәрдә боегам.
Гел болыт эчендә яшәүдән
Җәмгыять, кешелек оеган.

Күкләргә карасаң, сорылык
Җаннарны суыра үзенә...
Кояшлы киләчәк каршына
Сыгылмый бар гына, түз генә...

«Исәнме, кояшым, исәнме!» –
Диярмен. Син бары чык кына.
Күземдә – өметтән яралган,
Җаныма таралган чык кына...

*2009 – 2010*

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА

*(8 Март уңае белән)*

Кочак-кочак чәчәк
Сезгә бүләк булсын,
Күңелегез шатлык,
Аклык белән тулсын!

Сезгә генә бүген
Якты кояшлы көн,
Бәхетегез булсын
Кояштай бербөтен!

Сөенегез әле,

Ямьле язны күреп,
Язның матурлыгын
Җаныгызга үреп.

Елмаегыз әле
Шул мизгелдә, хәзер.
Без бит сезнең өчен
Барсына да әзер!

*2010*

ӘЙТЕЛӘ СҮЗЛӘР, ӘЙТЕЛӘ...

Әйтелә сүзләр, әйтелә,
Кайчак дуламыйча да.
Үзләре телгә киләләр,
Кайчак уйламыйча да.

Бу сүзләр туры һәм дөрес,
Кырыс та, аяусыз да.
Дошманнарны бәреп ега
Чирүсез дә, яусыз да.

Дусларны да үпкәләтә,
Хәтта сөйгән ярны да.
Туры сүзләр туры бәрә
Иң оста татарны да.

Туры әйткән туганына
Ярамаган, диләр дә...
Нишләтәсең, шагыйрь җаны
Ауный алмый идәндә.

Әйтелә шул, ни хәл итим,
Авыр суламыйча да.
Авыздан чыгып китәләр,
Кайчак уйламыйча да.

*2010*

* * *

Кызыл куртка кигән бер кыз,
Кызыл шарф бәйләгән. –
Кызыл машинасы белән
Бүген шәһәр әйләнә.

Ул сөйгәнен эзли микән?
Әллә болай гынамы,
Машинасына утырып,
Кич шәһәргә чыгамы?..

Тыз-быз чаба машиналар,
Кызыллары күренә...

Гүя кызыл карлар ява
Кызның күңел түренә...

Явар да шул, сөйгәнеңне
Машинада эзләсәң.
Тирә-юньне караланган
Тәрәзәңнән күзләсәң...

Кызыл куртка кигән бер кыз,
Кызыл шарф бәйләгән... –
Чү! Кызыбыз җәяү генә
Бүген шәһәр әйләнә...

*2010*

# АГА БАЗАР

ЧУЕН ГӘРӘЙ МАЛАЕ

*Мәгъсүм Гәрәевкә*

Аслы-өсле заманасы,
Бар ярлысы, бар бае...
Дусларга, шәкертләргә бай
Чуен Гәрәй малае...

Зәңгәр күкнең кояшы бар,
Серле төннең ак ае...
Әллә каян балкып килә
Чуен Гәрәй малае.

Бөтен җирне айкап чыккан
Гади татар агае...
Гел кешеләр арасында
Чуен Гәрәй малае.

Дөнья көткән ир-атларның
Бар чанасы, бар тае...
Кулда – каләм, җанда – ялкын –
Чуен Гәрәй малае.

Гомер булгач, була инде
Алае да болае...
Җиде-җитмеш арасында
Мәгъсүм – Гәрәй малае.

*2005*

ШАГЫЙРЬ ГОМЕРЕ

Сулыш тынып калыр
ничәнчедер биттә...
Каләм сынып калыр
һәм тилмерер читтә.

Илһам арттан барыр:
«Китмә инде, китмә!..»

...Тормыш алга чабар,
күчәр биттән биткә...
Шагыйрь гомре һәрчак
тора ике чиктә...
*2005*

БҮГЕН СИҢА МЕҢ ЯШЬ, КАЗАН!..

Казансу киң ярларына
Мең дулкыннан мең чаң кага.
Үткәннәрнең моңы булып
Күктән ап-ак болыт ага.

Кабан күле… Болак буе…
Таш диварлар балкып тора.
Кояшка таҗларын ачкан
Гөлдән хуш ис аңкып тора.

Сөембикәң, горур Тукай
Сәлам бирә әллә каян.
Таңда искән Идел җиле
Үзе уйнак, үзе шаян.

Кол Галиең, Кол Шәрифең
Гасырлардан карап кала.
Киләчәкнең чыңы булып
Күктән ап-ак болыт ага.

Бүген сиңа мең яшь, Казан!..
Бар җиһанга эндәш, Казан!..
Ун гасырны вакласаң да,
Син һаман да гел яшь, Казан!..

*2005*
И МОСТАЙ…

*Мостай Кәрим истәлегенә*

И Мостай, Мостай идең…
Ут уйнаткан тай идең.
Ике туган арасында
Мәңге сүнмәс ай идең…

И Мостай, Мостай идең…
Син көчле, ыспай идең.
Татарны да, башкортны да
Дуслыкка кыстай идең…

И Мостай, Мостай идең…
Син бәхетле, бай идең.
«Озын-озак балачак»тан
Үр менгән коштай идең…

И Мостай, Мостай идең…

*2005*
МОХТАР МУТИН

Үз балаңны, илем, талаттың син,
Эткә талаттың...
«Ә мин сине соңгы сулышта да
Өзелеп яраттым...»

Отеллоны уйнап йөрдең
Сәхнә түрләрендә.
Фәрештәләр күтәрделәр
Иҗат үрләренә.

Гади авыл малаеннан
Трагик артист булдың.
Тамашачың күңеленә
Бер моң булып кундың.

Такталачык урамнары
Сине хәтерләтә.
Дошманың түләде сиңа
Хәйлә-мәкерләтә.

Яго ролен килештерми,
Синнән көнләште.
Кара козгын тарафына
Ялган эндәште.

Төнге күкне өнәмичә,
Йолдыз атыла.
Рәшәткәләр арасында
Ярсу Отелло.
Себер тараф... Колымага
Илтер юлларың.
Артисттан да кол ясыйлар –
Бәйле кулларың.

Бер кат түгел, мең кат чылбыр
Аякларыңда.
Спектакльдән калган пудра
Яңакларыңда...

Такталачык урамнары
Сыкрап куйдылар.
Казандагы афишаңа
Корым койдылар.

– Кайда безнең Мохтар? – диеп
Әйтмәде беркем.
Сорасалар, хәл иттеләр,
Җиткәндер бер төн.

Төшләреңдә йөдәтәдер
Сәхнә утлары.

Синең урында Яголар –
Тормыш шутлары.

Уйный алар Отеллоны,
Рольләргә кереп.
Халык кына ышаналмый,
Утыра көлеп...

...Күп көтмәде, «агач ящик»
Уйнады тормыш.
«Эх, яшисе килә минем,
Туймадым, тормыш!..»
Такталачык урамнары
Өзлегеп калды.
Ярты юлда сүнмәс моңың
Өзелеп калды...

...Еллар үткән, Яголарның
Эзе калмаган.
Синең кайнар исемеңне
Гөлләр камаган.

*2004 – 2005*

* * *

Зур талантлар урам себергән җир,
Шыр наданнар шартлап симергән җир...
Ә уллары Айга җитә алган,
Китә алмам синнән, китә алмам...

*2005*

* * *

Коймага язылган сүзләрне
Яңгыр да юалмый, ак кар да!..
Мең еллык горурлык эчендә
Биш йөзлек сабырлык татарда!..

*2005*

ЯМАДЫ...

*(Илдар абый Юзеевны уйлап...)*

Бер ел үтә ак карлары белән...
Күңелләрне сагыш камады.
Ни хәлләрдә икән ялгыз калган,
Ак каеннар үскән Ямады?..

Зур Казанга салган гомерләрнең
Иге-чиге генә чамалы...
Ни хәлләрдә икән борын төрткән,
Башкортларда калган Ямады?..

Ул тарафта – туган нигеземдә –
Татарларга урын калмады.

Яши микән, сулый микән әле
Богауланган җаным – Ямады?..

Дөнья дигән боксер йөрәгемә
Әллә ничә тапкыр ямады.
Китсәм дә мин, мәңге синдә калам,
Бала чагым үткән Ямады...

*2005*

## БАР ДӨНЬЯ ТАНЫГАНДА...

*Минтимер Шәймиевкә*

Татарга авыр дәвердә
Юлдашчы кирәк иде.
«Барыйк, – диеп, – бергә-бергә», –
Юлбашчы кирәк иде...

Милләтнең үткән сукмагы
Тонықланган чакларда,
Күршенең күсәк-тукмагы
Борылгач бу якларга,

Уртак тел табу да кирәк,
Сөйләшә белү кирәк.
Күңелдә бары бер теләк:
Көрәшә белү кирәк.

Төрле юллар эзли-эзли,
Алдашырга юл куймый...
Тик утырып йөрәк түзми,
Үзенә яра уймый.

Тел югалган дәверләрдә
Саклана белү кирәк.
Кысулардан, җәберләрдән
Яклана белү кирәк.

Татар яши ду китереп,
Хокукын даулый-даулый.
Беркем дә, аңа җикереп,
Ирекен ала алмый.
...Татарның халык икәнен
Бар дөнья таныганда,
Киергән ап-ак җилкәне
Күренә анык анда!..

*2005*

## СКРИПКА

Күңелләрне теләсәң бит,
Син үзең дә беләсең бит
Җанга ничек чирткәнеңне.

Сине ничек көткәнемне
Сизәсең лә, тоясың ла…
Скрипка, скрипка,
Бар кайгымны коясың ла!..

Чегәннәрнең тирмәләре,
Кызларының бирнәләре,
Шартлап янган учаклары,
Утта курган борчаклары
Искә төшә бер-бер артлы…
Скрипка, скрипка,
Синең моңың бер мең катлы!..

Иоганның* кызулары,
Әрнетепләр сызулары
Йөрәкләрне уйнаттыра,
Гомер юлын уйлаттыра,
Якын затмы, әллә ятмы…
Скрипка, скрипка,
Бер ишетү – бер мең шатлык!..

Яшь гүзәлнең сине кочып,
Нәзек кулы белән кысып
Уйнаулары күккә илтә.
Сөю иңә көлтә-көлтә –
Шыбырдашкан тамчы чыңы.
Скрипка, скрипка,
Син – әкият, чынның чыны!..

Бабамнарның пулатлары,
Яуга чапкан көр атлары,
Әбиемнең кул болгавы,
Кылларымда мең уйнавы
Төнне ялгап, таң аттыра.
Скрипка, скрипка,
Мең сөйдертә, мең тилертә,
Мең көйдертә, яраттыра!..

*2006*

ЖАННАР – ИРЕКЛЕ!..

*(Мохтар Мутинны уйлап...)*

Нахак ягып, сөргеннәргә сөреп,
Ач этләргә ташлап үтерден дә...
Хәзер инде аклап маташасың,
Күләгәңә кояш китерден дә.

Гаеплисең, әйтерсең син – Алла,
Ярлыкыйсың Ходай шикелле...
Кешеләргә хуҗа,
                ә җаннарга

Тешең үтми, алар – ирекле!..

Аклыйсың син, бер дә акланмыйсың,
Гөнаһларың ашкан муеннан...
Су юарлык «изге» караш йөздә,
Элмәк чыгып тора куеннан...

Акланма син, акланма син, Рәсәй,
Синең тарих тоташ кан гына.
Үткәннәрдән килгән ташка бассаң,
Кара таштан сыкрап кан чыга...

Талант җаны эчтән дөрләп яна,
Син сибәчәк бозга ул бикле.
Кешеләргә хуҗа,
                    ә җаннарга
Кулың җитми, алар – ирекле!..

*2006*

ТУКАЙ КАЙТА!..

Язлар белән күңелләргә Тукай кайта,
Пар атларда Казанына килгән кебек...
Бөтен халык телсез калып карап тора,
Бар кайгысын, мәшәкатен җиңгән кебек...

Каеннарда берәм-берәм бөре төртә,
Күңелләрдән саркып чыккан хисләр кебек...
Шигъри ямьне, пәйгамбәрне көткән чакта,
Сизгер йөрәк түзмәс, әллә нишләр кебек...

«Пар атларда Тукай кайта!..
                                Тукай кайта!..»
Ераклардан балкып торган изге кыйбла.
Иман сызлар...
                Имансызлар соң минутта
Тукаеның каршысына килеп егыла.

*2006*

ЮГЫЙСӘ...

Тышта суык җилләр исә,
Күңелемне кисә-кисә.
Хәтеремдә, әле кичә
Алай түгел иде югыйсә.

Дөнья кайный, дөнья шаулый,
Нигә шунда шартлап аумый,
Көмәннәрен җилгә атып,
Ап-ак каен – ап-ак хатын.

Нигә шунда чәчелмиләр,
Ник кара тәре элмиләр,
Мөһер сугып булачакка...

Утын атам ут-учакка...

Ялкыныма кош коела
Канатланган яңгыр булып.
Уяныла, мең оела...
Йөрәк тибә сулык-сулык.

Нечкә күңел – скрипка,
Килербезме юньгә-ипкә?..
Җилләр исә, җанны кисә,
Алай түгел иде югыйсә...

*2006*

ӨЧӘҮ

*(триптих)*

*Авылдашларыма*

1

Мохтар Мутин

Син беренче һәм соңгысы,
Син бунтарь һәм син тынгысыз.
Биеп янган ут диярсең,
Җитди, үзе мут диярсең...

Сәхнә өчен тугансыңдыр...
Колымада туңгансыңдыр...
Чын дөньясы шулдыр аның –
Себер якта калды җаның.

2

Гамил Афзал

Син җор телле, үткен телле,
Кайчак усал, кискен телле.
Синең каләм очкын чәчә,
Офыкларда бии рәшә...

Иҗат өчен тугансыңдыр...
Магниткада туңгансыңдыр...
Чын дөньясын син беләсең:
Кулак дип тә сөреләсең.

3

Альберт Фәтхи

Син тырыш, син омтылучан,
Тик күзләрең уйчан-уйчан.
Шәмең яна куышында,
Үткәннәрнең юлы шунда...

Тарих өчен тугансыңдыр...

Казанда да туңгансыңдыр...
Чып-чын дөнья шушы инде:
Ялгыз янган шәмең сүнде...

*2006*

* * *

Оегансың, йончыгансың,
Болай барсаң, тончыгасың.
Урыс белән төн чыгасың,
Әле бар күп көн чыгасың.

Күпме була тилмерергә,
Вакыт инде җимерергә
Богаулаган арканнарны.
Таянырга аркаң бармы?..

Теге кыса, бусы кыса,
Бөтенесе вакытлыча...
Тик синең тарих дәвамлы,
Кол Галиле, «Бәдавам»лы...
Күпме сүзләр сөрсеп ята,
Ә китаплар тулы хата.
Каләм дә бар, дөреслек тә,
Утырабыз бер өслектә.

Баш катыру уен эшме?
Күңелләрне уеп төште
Йокылыкның салкынлыгы,
Йөрәкләрнең ялкын югы...

Төн чыкканчы, йон чыккан, ди,
Икенчесе тончыккан, ди...
Вакыт, вакыт!.. Боз кузгалды,
Күтәрик тузган тузларны!..

*2006*

БЕРГӘ БАРАСЫ...

Менә тагын сиңа барам,
Син бит – минем йөрәк ярам,
Башкортстан, Уфа каласы,
Безгә һәрчак бергә барасы.

Дошманнар күп тырышмасын,
Өстән, яннан булсын басым,
Бер ананың ике баласы –
Безгә һәрчак бергә янасы.

Син җаныма үз һәм якын,
Табигатең, горур халкың...
Гомерләрне бергә санасы,
Безгә мәңге бергә каласы.

Казан – минем йөрәгемдә,
Тоям Уфа кирәген дә.
Йөрәгемә алып саласы,
Башкортстан, Уфа каласы.

Ерак түгел безнең ара,
Туган туганына бара...
Башкортстан, Уфа каласы,
Безгә һәрчак бергә барасы...

*2006*

## АГА БАЗАР

Ага базар, ага базар,
Гүя утлы таба базар...
Әби-карчык күп йон язар,
Оек бәйләр, ак шәл бәйләр,
Үтәр язлар, үтәр җәйләр...
Ә хатыннар ак май язар,
Сөт өстеннән әйрән сыгар –
Ап-ак икмәк, кымыз чыгар!..
Карт бабайлар тәнен язар,
Арба ясар, чана ясар,
Итек тегәр,ката басар...
Ә ир-атлар канын язар,
Тимер чүкер, кылыч ясар –
Мичен ябар, мичен ачар...
Япь-яшь кызлар сөю язар, –
Мендәр эшләр, чигү чигәр.
Аһ, уңганнар!.. Нинди чибәр!..
Яшь егетләр сөяк язар,
Ат чаптырыр, колын карар,
Ары чабар, бире чабар...
Сәүдәгәргә бәхет язар,
Бәрхет ситса, ефәк кенә,
Гүя йомшак түшәк кенә...
Пешкән җимеш, кипкән җимеш,
Аша юып, шушы килеш.
Яңа күлмәк, яңа ыштан –
Кисәң яза күрмә һуштан.

Ага базар, ага базар...
Иске базар, яңа базар.
Алыш-биреш, сату-алу,
Учка алтын, көмеш салу.
– Бер алтынга...
– Унбиш көмеш...
– Ярый, алам шушы килеш... –
Ыгы-зыгы, сатулашу,

Шау-шу гына, татулашу...

Һәр көн саен ага базар...
Тарихчылар тарих язар...
Киләчәккә соң ни язар?..
Ага базар, ага базар...
*2006*

КАШЛЫ ЙӨЗЕК

Йөзек кашы, йөзек кашы,
Ымсындыргыч йөзек ташы.
Ак бәхеткә илтә торган
Гомер башы – сөю башы.

1

Кашлы йөзек, кашлы йөзек,
Ялтыр-йолтыр ташлы йөзек.
Дәүләт төзек, илләр төзек,
Кызлар йөри гөлләр өзеп.

Бармагында кашлы йөзек,
Сөюгәме башмы йөзек?..
Егет йөри дөнья гизеп,
Өйдә көтә «кашлы йөзек».
Хан кулында кашлы йөзек,
Хатынында ташлы йөзек,
Йозакланган ишекләрне
Көтмәгәндә ачты йөзек.

2

Гомер бара, еллар бара,
Көннәр кара, гөлләр кара.
Егет үлгән, кыз – кәнизәк,
Бармакларын тормый бизәп

Кашлы йөзек, кашлы йөзек,
Ымсындыргыч ташлы йөзек.
Ялварулар өзек-өзек,
Җанны куя өзеп-өзеп...

Кашсыз йөзек – илсез йөзек,
Башын игән телсез йөзек...
Булыр микән кире төзеп,
Кашлы йөзек, кашлы йөзек?..
*2006*

ЯҢАРЫШ

...сАФ ЗАЛ*ларда йөрим ялгыз гына,
жалЮЗИ**ны киереп ачам да...
иртәләрГӘ РӘЙ***хан исе сеңгән,

көн җыена яңа башламга...

*2006*

ТАТАРЫМА

Үзеңне үзең бүләсең,
Гел болай булмас, күрәсең...
Татар, татар – ул бер генә,
Түгел нокта, өтер генә!

Татар – горур, татар – өндәү,
Татар – олы, татар ул – дәү!
Татар – бөек, шаулый җиһан,
Татар – хуҗа, татар ул – хан!

Татар – Болгар, татар – Биләр!
Һәр тарафта: «Татар!» – диләр.
Татар – җитди, курку белмәс,
Башын имәс һәм баш бирмәс!

*2007*

КИЛЕП КИТҮ КИРӘК...

*Мөдәррис Әгъләмгә*

Килеп китү кирәк, килеп китү,
Халкың күңеленә кереп китү,
Җаны-бәгыренә сеңеп китү,
Биек таудан күккә менеп китү...
Килеп китү кирәк, килеп китү...

Күреп китү кирәк, күреп китү,
Гамьсезләрне гамьгә төреп китү,
Моңсызлыкны моңга үреп китү,
Һәрбер җанга җылы өреп китү...
Күреп китү кирәк, күреп китү...

*2006*

* * *

*Шагыйрь Зөлфәткә*
Күрсә дә ир
нужасын,
Аягыннан ега алмас
Шигъриятнең хуҗасын!

*2006*

ЮРАУ

Таң белән йолдызлар
Бик авыр суласа,
Җавап бер: бүген үк
Казанны су баса.

Су баса Казанны,
Кыш яуган кар суы,
Язларның җылысы,
Күңелнең ярсуы.

Мең еллык тузанны
Яз җиле актара;
«Бу Казан тыштан ак,
Ә эчтән кап-кара...»

Эченнән дым сарган,
Сыгылган ул Казан.
Үзенең яшенә
Тыгылган ул Казан.

Шуңамы агалмый
Бозланган яше дә...
Башына китерми
Карты да, яше дә –

Таң белән йолдызлар,
Һай, авыр суласа,
Җавап бер: бүген үк
Казанны су баса...
Су баса Казанны,
Юк, булмас кичерү.
Үткәнне-сүткәнне
Гел искә төшерү.

Һәм чәйнәү йөз еллык,
Мең еллык тарихны.
Без әле Казанлы,
Без әле тарихлы!..

Булса да диварлар
Ап-акка манылган.
Аларга күпләрнең
Карашы кагылган.

Карамы карашы,
Изгеме карашы.
Куера Казанда,
Куера кар ашы.

Таш ташка сүтелгән
Тузанын өйләрнең
Мин сиңа, җай чыккач,
Әле бер сөйләрмен...

Тик бүген каралган
Казанны су баса.

Ни булыр, йөз еллык
Өрене юмаса?..

Сеңдереп калдырса
Ак дивар ташына,
Кем килер аннары
Тук баба ашына?

Тыштан ак, ә эчтән
Кара ул, кап-кара...
Бабайлар калдырган
Хыяллар таптала...

Фал ачык: күңелләр
Барсына чыдаса,
Таң белән йолдызлар
Бик авыр суласа,
Бүген үк Казанны
Мәңгелек су баса!..

*2007*

* * *

Яз бавының очы югалган,
Эзләп карыйм микән Уралдан?..
Йолдызларның нуры кимегән,
Эзләп карыйм микән Иделдән?..

Карурманның шомы сүрелгән,
Сорап карыйм микән бүредән?.. –
Җидегән чишмә ага тамчылап,
Ал шәфәкътан яңа таң сорап.

*2007*

* * *

Ерак-еракларга барып чыга
Безнең буыннарның бәйләнеше.
Күпләр киткән ал офыкка таба,
Миңа калган бары бәйләм очы.

Миңа бары бәйләм очы калган,
Иман белән иманадан килгән.
Әнә минем мулла бабайларым
Ап-ак чапан, яшел чалма кигән.

Яңа гасыр ишек каккан мәлдә,
Үз мәчете, мәдрәсәсе булган.
Диварларга кунган киштәләргә
Акыл-гыйлем булып китап тулган.

Сабак укый бабам шәкертләре
Кол Галидән, Шиһаб Мәрҗанидән.

Өсләрендә ап-ак киндер күлмәк,
Кәләпүшләр башта – кичә кигән.

«Җиде йортның телен бел икән лә,
Җиде төрле белем бел икән лә.
Без барасы юллар туры икән,
Без барасы юллар бер икән лә...»

...Манарадан азан әйтә кемдер,
Кичә – бабам, бүген улыдырмы?
Тарих хәтерләре бөтен микән,
Тарих илткән юллар турыдырмы?..
Кем әйталсын, гомер әйтерсең көй,
Тартылган кыл буйлап узып бара.
Бабамнардан калган изге китап –
Ә битләре аның тузып бара.

Ерак еракларны ялгап тора
Безнең буыннарның бәйләнеше.
Иман киткән ак офыкка таба,
Миңа калган җылы бәйләм очы.

*2007*

* * *

*Фәнис Яруллинга*

Биек таулар, киек таулар көтә,
Кайсысына менү – синең эш.
Бер дөрләсәң, бер үрләсәң әгәр,
Мәңге булмас артка чигенеш.

Күпме сынау – бишәү, унау... көтә,
Тау башында көлә кояшы.
Өскә менеп, халкым күңеленә
Кояш нурын килә коясы.

Шатлык, бәхет арта менгән саен,
Якыная күкнең түбәсе.
Без күп күрдек, җанга җылы тордек,
Йолдызларны килә үбәсе!..
Биеклектән курыкмыйсың ла ул,
Җан чыныккан эссе-салкында.
Күз нурларым һәм җырларым минем
Татарыма, газиз халкыма.

Мин биектә, айга күпер сузам, –
Һич туктамыйм кичен, көндез дә...
Күккә багып, Зөһрә кызны табып,
Айны бүләк итәм мин сезгә!
*2008*

* * *

*Галина Казанцевага*

«Алтынчәч»нең мөнбәреннән
Дәшәргә базам сиңа,
Галина Казанцева!

Ак кәгазь битенә мин дә
Бер шигырь язам сиңа,
Галина Казанцева!

Миннән бүләк – бәхет тулы
Зур алтын казан сиңа,
Галина Казанцева!..

Бар дөньяны яңгыратып
Алкышлый Казан сиңа,
Галина Казанцева!

*2008*

* * *

*(Габдулла Тукай яшәгән*
*«Болгар» кунакханәсенә мәрсия)*

Хуш, исән бул, Тукаемның
Җанын саклаган бина.
Ятимне – бөек шагыйрьне –
Кире какмаган бина.

Йөрәктәге тирән ярам,
Бәлкем, бер төзәлер дә...
Тик кем генә җөрьәт итте
Сиңа кул күтәрергә?!

Кем уйлаган шагыйрь хакы
Булыр бары чүп диеп,
Тукай өчен изге бина
Артык диеп, күп диеп.

Ятим җанын дәваларга
Ул сиңа ишек каккан.
Тукайның әнисе бит син,
Ул синдә оя тапкан!

Якты бүлмәләр эчендә
Күпме шигырь тугандыр...
Акшарланган диварларны
Илаһи моң югандыр.

Хуш, исән бул, Тукаемны
Үз иткән изге бина.

Дога кылырга теләсәм,
Мин килә алмыйм сиңа...

Син юк инде, изге «Болгар»... –
Милләтем, бу нишләвең?..
Сине уятырга теләп,
Иренемне тешләвем.

*2008*

* * *

*Роберт Миңнуллинга*

Роберт абый алтмышта, ди,
Әллә чын, әллә ялган?!
Шагыйрьлек әләмен тотып,
Ул атлап бара алдан.

Аның җырларын җырлыйлар,
Шигырьләрен сөйлиләр.
Роберт абый алтмышта бит,
Әллә шуны белмиләр?

Үзе бала, үзе абый,
Үзе бабай түгелме?..
Ә барыбер аны күрү,
Аны тыңлау күңелле!
Бер карасаң, алтмыш яшьтә
Пенсиягә вакыттыр...
Ә син озак итеп картлык
Ишекләрен шакып тор.

Ачмасыннар, кертмәсеннәр
Сине шушы ишектән.
Сине балалык үз иткән,
Яшьлек үзе иш иткән.

Яз, иҗат ит, җидетомлык –
Ул бит әле чик түгел.
Яңа әсәрләрең кирәк,
Алар безгә чит түгел!

Алтыдагы – алтмышка, ди,
Сигездәге – сиксәнгә.
Мактый гына алам сине,
Нәрсә генә дисәң дә!

*2008*

АКТАНЫШ

Актаныш – көч, Актаныш – төш,
Актаныш – таш.
Актаныш – көй, Актаныш – өй,
Актаныш – баш.

Актаныш – чың, Актаныш – моң,
Актаныш – көн.
Актаныш – тын, Актаныш – чын,
Актаныш – өн.

Актаныш – җан, Актаныш – кан,
Актаныш – таң.
Актаныш – буй, Актаныш – уй,
Актаныш – аң.

Актаныш – гер, Актаныш – гел,
Актаныш – бер.
Актаныш – үр, Актаныш – түр,
Актаныш – сер.

Актаныш – ай, Актаныш – бай,
Актаныш – мул...
Бар татарга берәү булган
Актаныш ул!

*2009*

АЛЬБЕРТ ФӘТХИ

*(поэма)*

Аркасында биштәр,
Ә башында кипке...
Ул ялгызы гына
Олы юлдан китте.

Барыр юлы озын,
Барыр юлы озак.
Адым саен көтә
Серләр тулы йозак.

Өянкеләр шаулый,
Яулык болгап кала.
Такталачык җанын
Сагыш чолгап кала.

Берәм-берәм китә
Канатланган бала...
Үз янына дәшә
Шау-шу баскан кала.

Гомер дәвам итә,

Буын алышына.
Еракларга китә –
Заман ярышына.

Аркасында биштәр,
Ә кулында китап...
Булмас икеләнеп,
Үткәннәрне бутап.
Күпме ишек тора,
Ачканнарын көтеп.
Укылмаган китап
Ята, җанны өтеп.

Актарырга кирәк,
Тузаннарны коеп,
Татарлыкны тоеп
Һәм барлыкны тоеп.

Нинди язмыш икән
Кәгазь битләрендә?..
«Әл-пи-ти-си» дигән
Язма читләренә...

Халык аңламый шул,
Халык белми әле.
Күпме истәлекләр
Дәшми, көлми әле...

Өем-өем китап,
Өстәлендә шәмдәл.
Бии-бии яна
Тамчы-тамчы шәмнәр...

Көнне төнгә ялгап,
Нур балкыта бина.
Шыпырт кына сулый
Әбүгалисина...

Аркасында биштәр,
Ә башында кипке...
Ул ялгызы гына
Татар буйлап китте.
Күпме китап ята,
Ачылганын көтеп.
Тыныч кына булмый
Авыллардан үтеп...

Яңгыр коя тышта...
Юллар күптән ап-ак...
– Абзый, синдә юкмы
Элеккеге китап?..

– Белмим, истән чыккан,
Әйдә, өйгә кер соң...
Эшең изге, улым,
Ходай ярдәм бирсен...

Авыл арты авыл,
Атна арты атна.
Кемдер басып тора
Буранлаган чатта.

Уйлар шундый ерак,
Уйлар шундый чыдам.
Ап-ак кипке кигән
Берәү бара юлдан.

Күңелләрдә йөри
Китап язмышлары.
Кара булып сеңгән
Шатлык-сагышлары...

Патша кызын сөйгән
Бер көтүче улы.
Тик мәхәббәтенә
Ябык икән юлы...
Хан сарае көтә,
Читтән яучы килгән.
Патша чибәр кызын
Карт кенәзгә биргән...

Үткән гомерләрне
Җилләр пыш-пыш сөйли.
Ә ул һаман юлдан
Аякларын сөйри...

Безнең тарих озын,
Безнең тарих тирән.
Үткәнеңне белсәң,
Бай булырсың, дигән...

Син изгелек эшлә,
Рәхмәт әйтер халык.
Һич югында, белер
Елгадагы балык...

Юллар шундый озын,
Гомер шундый кыска.
Еллар үтмәделәр
Бер кайгысыз, бушка...

Аркасында биштәр...
Әнә кайтып килә!..
Китап булып йөри,
Керә өйдән өйгә!..

*2006*

ЗӘҢГӘР КҮЗЛЕ ӘТИ

*(поэма)*

Күренекле педагог, Бөек Ватан сугышы ятимнәренең газиз әтиләре, Актаныш районының 4 нче номерлы Яңа Әлем һәм 3 нче номерлы Такталачык балалар йортлары директоры, РСФСРның халык

мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы, кадерле дәү әтием Нәҗип Газиз улы Газизовның якты истәлегенә багышлыйм.

1

Күпне күргән караш,
Тирән йөзгән уйлар.
Безнең китеп барыш,
Оныклар ни уйлар?..

Эшләнгәннәр күпме,
Эшлиселәр күпме.
Шушы изге юлда
Күз нурларын түкте

Тырыш һәм иманлы
Олы җанлы затлар.
Алар безнең белән
Гел янәшә атлар...

Алар сезнең белән
Һаман бергә булыр.
Искә төшсә әгәр,
Күзгә яшь тыгылыр...

2

Без туган чор – көчле
Инкыйлаблар чоры.
Пулеметлы, атлы
Горур аклар чоры.

Азатлыкка чапкан
Хөр кызыллар чоры.
Ачлык аша үткән
Кызлар-уллар чоры.

Газиз әти – мулла,
Һәм абыстай – әни.
Ак биләүдә ята
Зәңгәр күзле бәби.

Киләчәккә карый
Мөлдерәмә күзләр.
Алар күпне күрер,
Алар күпне күзләр.

Ак биләүне кыскан
Нәни, нәзек куллар.
«Тырыш бала булыр» –
Ата шулай юрар.

Ана бишек көен
Сузар талгын гына.

Ак бүлмәдә йөрер
Иманлы моң гына.
...Бөтен авыл бүген
Намазлыкка баскан.
Ә абыстай, җаный,
Яңа дөнья ачкан –

Иш янына кушмы,
Ул янына – кызы.
Көлдә тәгәрәшә
Кызган борчак кузы.

Җил актара көлне
Һәм туздыра гына...
Инкыйлаблар җанны
Гел кыздыра гына...

Кемдер ясин укый,
Кемдер яшен сөртте.
Мулла яшьли китте,
Мәңгелеккә китте.

Ике бала ятим,
Абыстай тол калган.
Яңарышлар килә –
Чынмы, әллә ялган?

Малай – анасына
Таяныч һәм терәк.
Ул белемле булсын,
Ул дөньяга кирәк!..

3

Күзләр бигрәк моңсу,
Сарыланган урман.
Сибәли вак яңгыр –
Җан өшетә торган.

Үзәкләргә үтә
Кышның суык җиле...
Үткән үткән инде,
Кайта алмас кире.

Бураннары бурый,
Юлларга көрт сала.
Киләчәккә таба
Тормыш шулай бара.

Яз да җитеп килә,
Ул күңелгә якын.
Зәңгәр күздә өмет,
Йөрәгендә – ялкын.

Әти салган юлны
Дәвам итәсеме?
Әллә инде башка
Юлдан китәсеме?

Минзәләгә илтә
Урау-урау юллар.
Шул тарафка бара
Бик күп кызлар, уллар.
Җәйге җылы рәхәт,
Җәйге җылы тансык.
Училище бүген
Һәркем өчен ачык.

Шунда укый хәзер
Зәңгәр күзле егет.
Күпне белә икән,
Нәкъ әтисе кебек.

Яңа таныш-дуслар...
Белемлеләр кирәк!..
Ярсып тора күңел,
Шашып тибә йөрәк.

Киләчәктә ниләр
Көтә икән сезне?..
Нәҗип белем алды,
Ул барсына түзде.

...Минзәләгә илтә
Туры гына юллар.
Аягында ката,
Өстә – сарык туннар.

Үги әти бара,
Кар көртләрен ерып.
Иртән юлга чыкты,
Таң атканчы торып.

Әзерләде ана
Төенчеген төйнәп.
Үги ата китте,
Моңлы бер җыр көйләп.
«Улым Минзәләдә,
Тагын берсе – өйдә...
Сагындырды зуры,
Их, күрәсе килә!..

Анасы да әйтә:
«Тамагы тук микән?
Күзе-мазар төшкән
Әйбере юк микән?..»

Өйдә калган кызы –

Әнисенә иптәш.
Җаннар юлда бергә,
Җаннар юлда чиктәш...

Ак биләүдә ята
Уртак балалары.
Җанны җанга бәйли
Уртак бала бары...

4

Өч ел бик тиз үтте.
Эх син, гомер, гомер!
Бала чакка йөгер,
Киләчәккә йөгер...

Күрше авыл көтә:
Укытучы килгән.
Күзе зәңгәр икән,
Үзе кәчтүм кигән...
Күңелендә кемдер?
Ә сөйгәне бармы?..
Яшел чирәм юллар
Бүген инде карлы.

Тик суытмый кышы,
Туган якта җылы.
Йөрәгендә йөри
Моңлы сөю җыры.

Кара чәчле бер кыз
Җанын биләп алган.
Эх син, яшьлек, яшьлек,
Йөз кат, мең кат алдан!..

Илдә сугыш бара,
Авыр еллар килде...
Зәңгәр күзле егет
Һаман белем бирде.

Бик тирәндә аның
Йөрәк яралары.
Өмет белән карый
Авыл балалары.

Башка чарасы юк,
Тылда хезмәт итә.
Яшьтәшләре көн дә
Яу кырына китә.

...Аның бүген туе.
Сау бул, егет чагым.
Гөрләп тора авыл,
Шаулап тора табын.
Кара чәчле шук кыз

Аның бердәнбере –
Үзе шундый ихлас,
Үзе шундый тере...

Киләчәккә алар
Икәү барачаклар.
Тормыш дилбегәсен
Учлап алачаклар.

5

Кичә сугыш бетте.
Илгә Җиңү килде.
Үстерергә кирәк,
Күтәрергә илне.

Яу кырында калды
Күпме батыр ир-ат.
Үзләре юк инде,
Кабер – зират-зират.

Балалары ятим,
Балалары ялгыз.
Борын тартып тора
Күпме малай һәм кыз.

Детдом директоры –
Зәңгәр күзле абый.
Аңа карап тора
Йөз-мең ятим сабый.

Аларга ул – «әти»,
Иң кадерле кеше.
Зур йөрәкле «абый»,
Киң бәгырьле кеше...

Әлем, Такталачык... –
Ул узасы юллар.
Кемдер рәхмәт әйтер,
Кемдер хатлар юллар.

Олы юлга чыгар
Сугыш балалары.
Көтә салалары,
Көтә калалары.

Бурычымны үтим,
Мин сүземдә торам.
Ятим балаларга
Яңа тормыш корам...

Күңел тулы сагыш,
Чык та сөйлә җилгә...
Алар кирәк миңа,
Алар кирәк илгә.

Зәңгәр күзле абый,

Зәңгәр күзле әти...
Башлы-күзле булды
Инде күпме ятим!..

6

Күпне күргән караш,
Тирән йөзгән уйлар.
Кемнәр генә, кайтып,
Үткәннәрне уйлар?..
Вакыт каударлана,
Вакыт кабалана.
Исән яшә, ата!
Исән яшә, ана!

Синең балаң үссен
Синең янда гына.
Калмасын ул ялгыз
Дөнья мәйданында!

Кеше киләчәккә
Сугышларсыз барсын.
Үткәннәргә карап,
Сабак, гыйбрәт алсын!

Зәңгәр күзле абый
Бездән алда атлый.
Әйтерсең ул һаман
Ятимнәрне саклый.

Аның изге эше
Меңнәрнең телендә.
Сүнмәс яктылыгы –
Халык күңелендә!

*2008*

ЭЧТӘЛЕК

Үз хисләрем шикелле. *Зөлфәт* ...............

**Кызыл алма**

Мин яратам, син – ярат *(җыр)* ..............
Бәхет шушы икән… .....................
«Син чиргә сабыштырасың…» ...............
«Син – оҗмахның алмасы…» ..............
«Йоклаганда, иреннәрем…» ................
«Диңгездә йолдыз бармы?..» ................
Син икән… .........................
«Чарасыз кырыкка ярылдым…» ..............
«Күктән төшкән йолдыз-җаннар…» ...........
«Йөрәгем түзалмый ут өрә…» ...............
Бәхет карлары *(җыр)* ....................
Синең исем *(җыр)* .....................
«Еллар арты еллар алышыныр...» .............
«Оялмадың, кызармадың…» ................
Айлар узды… *(цикл)* ...................
Таң кызына ..........................

«Уйларымны тараттың ла…» ...............
Син генә… .........................
Синсез яшәү *(җыр)* ....................
Кызыл алма *(җыр)* ....................
«Упкынга ташланам...» ...................
Бәхетем тулы түгел *(җыр)* ................
Көтә-көтә... .........................
Күз яшьләре алдамыйлар... ................
Кaурый сибәм... .......................
Якты тавыш .........................
Җанда уел кебек... .....................
«Уйлама, уйнама, юрама...» ................
Ярый, көтәм… .......................
«Сиңа миңа караганда...» .................
Килмә инде… ........................
Ул яз безнең өчен генә… .................
Сөйгәнемнең туган көне ..................
Августның соңгы кичләре… ...............
Лаеш?.. Актанышкача!.. ..................
Синсез төн .........................
Пар яфрак *(көзге җыр)* ..................
«Дым астында басып торам...» ..............
Яратам!.. ...........................
«Ихлас яшьләр елтырыйлар...» ..............
«Минем язмыш хата-ялгышлардан...» ..........
Коңгырт күзләр... .....................
Бәхетле ятимлек .......................
Шуңамы?.. .........................
«Үпкәләттем сине юкка...» ................
«Син мине ишетмисең...» .................
«Син киткәч, күңелсезләнәм...» .............
МСЯ!.. ...........................
Ярый әле син бар... .....................
«Җилкәй булып назлар идем...» .............
Сиңа багышланган шигырь .................
«Сине уйлыйм – син еракта...» .............
«Мин сине шунда ук сагынам...» .............
«Күңелгә яз кереп урнашты...» ..............
«Бүләк итимме соң сиңа...» ................
Шашкын йөрәк .......................
«Мәхәббәттән качып булмый ла ул...» ..........
«Шомыртлар чәчәккә күмелгән...» ............
Күзләрең... .........................
«Җәйге яңгыр яуганда да...» ................
Туй көнендә ........................
«Көн үтә, көн бара, көн чаба...» .............
Безнең туй көне .......................
«Минем йөрәк тип-тибә...» ................
Мин ............................
Син .............................
Без .............................
«Йөзең бүген балкып тора...» ...............
«Карыйм әле тын гына...» .................
«Ак бәхетләр яусын, яусын әле...» ............
«Синең күзеңә карасам...» ................
«Ләйсән яңгыр тамчылары...» ..............
Сиңа ............................
«Сөйгәнем...» ........................
«Тышта яңгыр...» ......................
«Җаныңда күпме борчу бар...» ..............
«Дөньяның чынбарлыгыннан...» .............
«Мин, сиңа карасам...» ..................
«Бер шигырь дә язмыйсың» дип...» ...........

**Халәт**

Ил гизүченең төнге җыры ................
Җәй үтеп бара сыман... ..................
«Күңелгә керә дә урнаша...» ................
«Дөньяның сынауларыннан...» ..............
«Шабыр тиргә батып уйлап ятам...» ...........
«Ава-түнә еллар аккан чакта…» .............
Ничек кенә яшәп калырга? ................
Син ташлама безне... .....................
«– Нигә кәефең юк?..» ..................
«Бозлар булып, карлар булып эри күңел...» .......
«Көйләр көйләп көй әле бер...» ..............
Җылытасы килә дөньяны!.. ................
Истәлек ...........................
Постмодерн ..........................
«Акыл сатмыйм бу дөньяга туганнарга...» .........
«Мәхәббәтне таптым дисең...» ...............
Дәү әниемне уйлап... *(цикл)* ................
«Йомгагың тәгәри-тәгәри...» ............
«Дәү әнисез калу авыр, беләм...» ..........
«Бүлмәң бигрәк бушаган...» .............
«Кемдер җитми җанга...» .............
«Кыш та килә көттереп...» ................
«Син – гүзәл күчмә кош...» ................
«Шәһәрнең шавына...» ..................
«Төн кап-кара...» .......................
«Кочагыма бөтен дөнья сыйган...» .............
«Эх, бермәл рәхәтләндереп...» ...............
«Борылам да карыйм үткәннәргә...» ............
«Җанымда җылы – бер уч...» .............
«Мин кояшка якын...» ...................
«Шигырьләрем шыгыр-шыгырдый...» ...........
«Тәрәз төбемдә – каеннар...» ...............
Көз. Казансу .........................
«Соң да түгел, түгел иртә дә...» .............
Алман дәфтәреннән *(цикл)* ................
«Сынаулар һәм сыналулар елы...» .........
Германиядә... ....................
Их!.. .........................
«Көзләр килә томырылып...» ............
Салым җыючыларга мөрәҗәгать ..........
Юксынам ......................
«Уйларның уйнар мәле...» .............
«Шап-шоп алма коела...» .............
Рәссам белән әңгәмә ................
Имәннәр... имәннәре... ...............
Оят! .........................
«Имән...» ......................
«Spaeter oder frueher...» ...............
Schreib mir... .....................
Алмания .......................
Чуагы... .......................
Көзләр... .......................
Сөйлә әле... .....................
Аккан сулар, искән җилләр... ............
«Әниеңне югалткансың икән...» ..........
Көзге яңгыр .....................

**Чын дөресен әйткәндә...**

Синең өлеш, минем өлеш… ................
Татлы хыял .........................
«Кояшта көз елмаюы...» ..................
Шигырь укыганда... ....................

Замана балаларына .....................
Суы беткән .........................
Чын дөресен әйткәндә... ..................
Вирусмы көчкән?.. .....................
Һәр ай саен бәйрәм... ....................
Берәүгә ...........................
Саташу ...........................
Буталыш ...........................
«Кы»лашу... .........................
Ачык күңел... ........................
«Студед» сүзе... .......................
Илһамланган мәлдә... ....................
Кая юкка чыктың?.. ....................
Сессия ............................
Мин ..............................
Кытайларга мәдхия .....................
Елатма... ...........................
Бур мәче турында әкият ..................
«Сук син, кыйна, камчыла...» ...............
Төшләнү ..........................
Бер күрәсем килә... ....................
Син моңайма, мәктәп! ...................
Бәхетсезрәк... ........................

**Гасырда фасыллар буталган...**

Кара-ак ............................
«Һәр адәм үзен кайгырта...» ...............
«Гомер буе «Халкым!» диеп...» ..............
«Әллүки» гимны ......................
«Йөзегең алтын икән лә...» ................
Туган якка кайта кеше... ..................
Гасырда фасыллар буталган... ...............
Яңа еллар килә… ......................
Хатын-кыз... ........................
Вакыт .............................
Яшәеш ............................
«Язны бутап, көзге яңгыр...» ...............
«Кысыр җәйне кысып...» ................
«Кара көйгән асфальт...» .................
«Эх, бу хәзергене...» ....................
Мантыйк ...........................
«Җәй димәссең...» .....................
Имәнкискәне уйлап... ....................
Туры... ............................
Танышу ...........................
«Зәңгәр күкне ярып оча...» ................
«Кызлар кызык эзләп йөри...» ..............
«Үткәннәрне онытырга кирәк...» .............
«Каударлана-каударлана...» ................
«Туң машина шавы...» ..................
Сентябрь иртәләре ....................
Ак күмгән сарылык .....................
«Бөтен дөнья бозык...» ...................
«Сары-сары сагыш...» ...................
«Ак каеннар шәрә-шәрә...» ...............
Йорт казлары зары .....................
Агымсулар... ........................
«Көзләр кышка тоташа...» .................
«Тәңкә-тәңкә карлар һаваларда...» ...........
Русия ............................
«Кубарылып, тугарылып...» ................
Карабаян ...........................
Берәүгә ...........................

«Тоташ соры пәрдә...» ....................
«Яуса яумый яңгыры да...» .................
Тәгәрмәч... ..........................
«Мин ышанам...» .......................
«Эссе җәйнең уртасына...» .................
«Каенны җил бөгә...» ...................
«Гомер узып тора...» ....................
«Ленар энем, мин бит белеп торам...» ..........
«Шыбыр-шыбыр...» ....................
«Чалма. Чапан. Сакал...» .................
«Яшьтән яшьлек йога...» .................
Кеше үтәсе юл .......................
«Яңа еллар котлы булсын берүк...» ............
Ярый әле туган авыллар бар ................
«Әллә нинди тормыш...» .................
«Булмаса да тулай торак...» ................
«Яфраклар яшел икән...» .................
«Күктә болыт...» ......................
«Урам тулы бомж этләр, бомж кошлар...» ........
«Безгә кадәр яшәгәннәр...» ................
«Бу телефон мәңге шалтырар инде» ...........
«Эшләр бар, эшләр күп...» ................
«И Ходаем...» .......................
Бәхет җыры .........................
«Исәнме, кояшым, исәнме!..» ...............
Хатын-кызларга ......................
Әйтелә сүзләр, әйтелә... ..................
«Кызыл куртка кигән бер кыз...» ............

**Ага базар**

Чуен Гәрәй малае .......................
Шагыйрь гомере .......................
Бүген сиңа мең яшь, Казан!.. ................
И Мостай… ........................
Мохтар Мутин .......................
«Зур талантлар урам себергән җир...» ..........
«Коймага язылган сүзләрне...» ..............
Ямады... ...........................
Бар дөнья таныганда... ...................
Скрипка ...........................
Җаннар – ирекле!.. ....................
Тукай кайта!.. ........................
Югыйсә... ..........................
Өчәү .............................
«Оегансың, йончыгансың...» ................
Бергә барасы... .......................
Ага базар ...........................
Кашлы йөзек ........................
Яңарыш ...........................
Татарыма ..........................
Килеп китү кирәк... .....................
«Күрсә дә ир...» .......................
Юрау ............................
«Яз бавының очы югалган...» ..............
«Ерак-еракларга барып чыга...» .............
«Биек таулар, киек таулар көтә...» ............
«Алтынчәч»нең мөнбәреннән...» .............
«Хуш, исән бул, Тукаемның...» .............
«Роберт абый алтмышта, ди...» ..............
Актаныш ..........................
Альберт Фәтхи *(поэма)* .................
Зәңгәр күзле эти *(поэма)* ................

Литературно-художественное издание

**Шаех** Ленар
(**Шаехов** Ленар Миннемохимович)

**Хочется согреть этот мир!..**

Казань. Татарское книжное издательство. 2011
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Шәех** Ленар
(**Шәехов** Ленар Миңнемөһим улы)

**Җылытасы килә дөньяны!..**

Мөхәррирләре *Э.Т.Кәлимуллина, Г.Ф.Сибгатова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.01.2011.
Форматы 70г90 $^1/_{32}$. Шартлы басма табагы 9,36.
Тиражы 2000 д. Заказ Р-84.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.